

# ТАТАР ХАЛЫК ТАБЫШМАКЛАРЫ



TURKISTAN KUTUBXONASI - ТУРКЕСТАНСКАЯ БИБЛИОТЕКА

http://www.turklib.ru

http://www.turklib.uz

http://www.turklib.com

# ТАТАР ТАБЫШМАКЛАРЫН

# ҖЫЮ ҺӘМ ТӘРТИПКӘ САЛУ ЭШЕ

## Нәкый Исәнбәт

**Б**орынгы зур сәүдә юлы булган Идел-Чулман елгасын кулга төшерү өчен, урта гасырларда өзлексез сугышлар барган. Шунда дәүләт корган Болгар, Алтын Урда, Казан җирләре шул сугыш зонасы булганга, шәһәрләре җимертелеп, таш өстендә таш калмаган, анда инде бик күп кулъязма әсәрләр яндырып көл ителгән, юкка чыккан. Шунлыктан -без ул чордан калган язма китап читләренә язып куелган берничә табышмактан 'башкасын таба алмыйбыз. Шулай да Алтын Урда дәүләте XIII йөзләрдәге Европада бердәнбер дип әйтерлек мәдәниятле Рим империясен бик нык (Сискәндергән һәм кызыксындырган; алар бу дәүләтне христианлык йоктырып эчтән алу хәйләсе белән миссионерларын йөртеп торганнар, моның өчен алар мәшәкатьле сәфәрләр ясап, ул чорның татар төркесен өйрәнергә мәҗбүр булганнар һәм бу телне өйрәнү өчен Италиядә, Венециядә, соңрак Парижда һәм башка җирләрдә төрки телләр институтлары ачканнар. Шул сәфәрләрдә язып алынган татар тел-әдәбият материаллары алар-дагы китапханәләрдә күп кенә сакланып калган. Кызганычка каршы, без әлегә кадәр ул материаллар -белән үзебез танышырлык мәдәни сәфәрләр ясый алганыбыз юк, күп нәрсә өйрәнелмәгән, хәтта билгеле дә булмаган хәлендә ята дип ишетелә. Без тик тюркологлар төзегән каталоглар һәм кайберсен алар җитешеп табып, шифрын ачып укып күрсәтүләре буенча гына беләбез.

Шулар арасында татар табышмакларының да тәү башлап XIII гасыр ахырында язып алынган булулары билгеле. Ул 1303 елда китап хәлендә теркәлгән Codecus CumanicusТа күренә. Анда 50 гә якын табышмак. Болар-арасында без төрдәшләре хәзерге телебездә дә әйтеп йөртелгән байтак кына табышмакларга очрыйбыз. (Мисалларын бу җыентыктан «Борынгы табышмаклар» бүлегеннән кара.) Татар табышмакларының язма рәвештә теркәлә 'башлануының башы, әлегә билгеле булганча, шушы.

Русларга килсәк, татар теленең көнчыгыш халыклар арасында рәсми тылмачлык ролен алар да дәвам иттерергә мәҗбүр булганнар. Ләкин үз мәмләкәтләрендәге халыкларның үзләрен, тел-әдәбият, фольклор һәм мәдәниятләрен якыннан гыйльми өйрәнү аларда бик соң, нигездә XIX йөздә генә башланган. Татар халык авыз иҗатын җыю, өйрәнә башлау да үткән йөздә генә күренә башлый. Шулардай безне .кызыксындырган татар

табышмакларына килсәк, тәү башлап 1838 елда Казан университеты студенты Мартиньян-Иванов тарафыннан «Татарская хрестоматия» дигән китабында беркадәр үрнәкләр җыелып, 1842 елда бастырып чыгарыла, (Минем җыентыкта аннан алынганнар «М.-Ив.» билгесе белән күрсәтеп барылалар.) Шуннан башка, 1892 елда Ветевский материаллары арасында басылган татар табышмакларын да искә алып үтсәк, рус гыйлем дөньясында безнең бу жанр иҗатыбызның теркәлгәне башкача күренми диярлек. (Катанов исә Каюм Насыйридагы табышмакларны гына алып бастырганга, яңа нәрсә өстәгән дип булмый.)

Көнбатыш Европада башлап Венгрия белгече Балинт Г.[*Балинт Г. «Казани-татар пүелвтан», Будапешт, 1877.*] керәшен татарларының фольклорыннан чыгарган җыентыгында 1877 елда 46 табышмак бастырган. Татарчасы латин хәрефләре белән бик дөрес итеп басылган.

Калган хезмәтләр татарларның үзләре тарафыннан эшләнгән. Алар шушылар:

1. М. Салихов; «Табышмаклар һәм һәртөрле халык арасында әйтелә торган мәкальләр», 1880 ел. Монда 39 табышмак кертелгән.

2. К. Насыйри. «Фәвакиһел җөләса», 1884 ел. 27 табышмак урнаштырылган һәм аңлатмалар бирелгән.

3. Яхин Т. «Саби вә сабияләр өчен мәргуб хикәяләр», 1900 ел. 88 табышмак урнаштырылган.

4. «Буквардян сунг укый торган книгя». Керәшен татарлар өчен чыгарылган татарча уку китабы, Казан, 1907 ел. Монда барлыгы 175 мәкаль һәм 115 табышмак. «Жомаклар» дип аталган. (81—91 битләр.) Керәшеннәр арасыннан җыелган.

5. Хуҗа Габделбәдигъ. «Халык әдәбияты», 2 нче бүлек, «Табышмаклар, такмаклар һәм такмазалар». 1913 ел (300 ләп табышмак).

6. Ареланов Г. «Бик кызык табышмаклар», 1910—>1913 еллар, 3 кисәк. Барлыгы 315 табышмак җыйган. Ләкин русчадан алынган һәм ясалма булганнары да күп.

Бу күрсәтелгән җыентыкларда барлыгы 400 чамасы табышмак теркәлгән. Алар, күбесенчә, бер-берен кабатлап, китаптан китапка күчкән мәгълүмрәк табышмаклар. К- Насыйри һәм Хуҗа Вәдигъ җыйганнан башкаларында гыйльми эзләнү яки җитди караш бар дип булмый, күбесенчә, юаныч һәм сәүдә әйбере булу ягыннан карап чыгарылганнар.

Революциядән бу як чорга килгәндә, татар табышмакларын «итап итеп чыгару бик сирәк эш булып киткән. 50 ел эчендә мин җыеп чыгарган «Табышмаклар» китабы бар. (Барлыгы 1468 табышмак, 1941 ел.) Моннан тыш, балалар өчен берничә битлек китапчыкны искә алмаганда, башкасы күренми.

Болар өстенә СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалы тарафыннан чыгарылган «Татар халык иҗаты» җыентыгында 500 ләп табышмак басылган. Боларда элеккеләр белән бергә яңалар да күренгәли. Балалар өчен чыгарылган фольклор җыентыкларында да, шундый чыкканнардан алып, үрнәкләр бирелгәләп килгән.

TURKISTAN KUTUBXONASI - ТУРКЕСТАНСКАЯ БИБЛИОТЕКА

Кыскасы, соңгы 50 елда элек җыелганнар белән бергә 500 ләп табышмак, алар белән бергә минем үткән җыентыкта бирелгән мең ярымлап табышмак һәм кулыгыздагы бу китаптагылар белән әлегә хәтле теркәлгәннәре күпме булуын чамаларга мөмкин булачак.

Инде бу җыентык турында бер-ике сүз.

Монда җыелган табышмакның 500 ләбе югарыда саналган мәгълүм китаплардан алынды. Калган иң зур күпчелеге минем тарафымнан озак еллар буена җыелган материаллар булып, аларның да иң зур өлеше укытучылык елларында укучы балалар авызыннан һәм укучы яшьләр арасында уздырылган фольклор кичәләреннән җыелды. Байтак кына табышмаклар туган авылым булган Малаяз авылыннан бала чагымда ук (1910—13 елларда) җиңгиләр, апалар арасында язып алынган булап, аларда типтәрчә сүзләр дә очраганы күренер. (1910 нчы елда җыйган бер дәфтәрчегем хәзер дә кулымда саклана.)

Тәртип-система мәсьәләсенә килгәндә, китап артындагы эчтәлек бүлегенә һәм китап битләренә күз салга-лап чыкканда, алар хакында" беренче тәэсирне алырга мөмкин. Аның нигезләре хакында укучы шушы мәкаләдән үзенә бер фикер хасил итә ала. :.

Җаваплары табышмаклар астына бирә барылды. Яндагы цифрлар табышмакларның сан тәртибен, юл ара саннар һәр табышмакның тема тәртибен күрсәтәләр. Кайбер табышмакларның үз яннарында ук аңлатмалар һәм тәрдәшләре дә бирелде. Алынган-табылган урыннары да табышмакларның үз яннарында ук күр-сәткәләп барылды. Җавап һәм төрле белешмәләрне читтән эзләүгә караганда, барын да табышмакның үз янында табу җайлырак булыр дип уйлыйм.

* * *

Бу китап сайланма җыентык түгел. Максат — татар табышмакларының тулырак бер җыелмасын бирү иде, Шулай булса да кулымда булган биш меңләп табышмактан бер меңләбе монда кертелә алмады.

Моның кайбер сәбәпләре бар. Шулардай берсе — соңгы вакытларда матбугатыбызны һәм дәреслекләре-безне һәртөрле тәрҗемә һәм ясалма яңа табышмаклар басып китүе. Халык хәзер укымышлы, күп кенә яшьләр табышмакны үзләре ясый алган кебек, бездә хәзер аның махсус авторлары да бар [*Минем үземнең чыгарган табышмакларым да бар. Туры килсә, аларны да берәр аерым урында бастырып чыгарырга исәп бар. Н.И.*]. Хәтта балалар да үзләреннән чыгарып әйткәлиләр. Анысы яхшы. Ләкин заманы шундый булгач, хәзер миңа да халык телендә йөргән табышмакларны аның саен тизрәк һәм күбрәк җыеп туплап калу өчен ашыгырга туры килде. Чөнки йоклап торсак, табышмакларыбызның халыкныкы булганнары белән булмаганнары чуалтылып, аларны аеру кыенга кала барачак...

Әнә ул төшереп калдырган табышмаклар күбесе шундый язма, тәрҗемә яки ясалма юл белән чыгарыл-ганнары булды. Шулай булса да андый язып чыгарылганнар арасында да кайбер уңышлылары һәм халыклашып киткәннәре, әлбәттә, бар. Шундыйларның халык аша алынган кайберләре бу җыентыкка да кертелгә-ләде. (Бу хакта аңлатмаларда күрсәткәләдем.)

Мондый зур җыентыкка алынган табышмаклар, табигый, бар да сыйфат ягыннан тигез, югары, шәп булып чыгалмыйлар. Кайберләренең «кызарып пешкән, өзелеп төшкән»

TURKISTAN KUTUBXONASI - ТУРКЕСТАНСКАЯ БИБЛИОТЕКА

булмаулары күренә. Арада андый йомшаграклары булу аларның күпчелеген укучы яшьләр аркылы җыюымнан да килә. Яшүсмерләрнең кайберсе әби-бабайларча шартын китереп әйтеп җиткерә алмаулары да табигый. Шулай да мин фольклор әсәрләрен мөмкин кадәр табылган хәлләрендә теркәү ягында булганга, аларны «редакцияләү»дән сак булырга тырыштым.

Табышмакларның тагы шактый гына зур бер өлеше чын халыкның үзенеке һәм сурәтчел :булса да монда кертелә алмады. Сәбәп шул, әлеге шуклык: китапка сыймый. Чөнки бит әле табышмакның зурны кечерәйтеп, кечене зурайтып, я -булмаса матурны ямьсез, ямьсезне матур күрсәтеп әйтүе бер хәл, ул әле юри әдәплегә салынган булып, бик сәнгатьчә итеп берәр яхшы нәрсәгә тиңләп оят җир турында, я шуның киресенчә, затлы гына бер әйберне юри затсыз нәрсәгә тиңләп, аты-юлы белән әйтеп бирергә дә күп алмый. Шуның аркасында җавабы әдәпкә сыйса, табышмагы сыймый, яки табышмагы сыйса, җавабы мәҗлес түренә узмыйча, төшеп кала.

Табышмакларның язылышында диалект һәм урынчылык аермалары сакланмады. Алар фәнни транскрипция буенча да бирелмәде. Шулай булса да, әйтергә кирәк, фольклор буларак, табышмакның үз специфик «теле» дә ;бар. Шундый якларын аз да булса киртәгә алу өчен, орфография һәм хәрефләребез җитешмәгәнгә, текстларда иң кимендә «йа», «йә» шикелле авазлар аерып язылды. Башка төрки халыклардан, әйтик башкорттан, алынган чагыштыруларда каты к, г ларны дөрес итеп күрсәтеп булса да, бездә исә, аптырагач, бик зарур урыннарда «къ», «гь» белән күрсәткәләргә мәҗбүр булдым. Шундый өлешчә генә төзәтүләр үткәндәге «Татар халык мәкальләре» китабында да бар, укучыларга ул бернинди авырлык китермәде, киресенчә, аз да булса җиңелләштергәне өчен рәхмәт кенә ишетергә насыйп булган иде.

Табышмакларның алынган урыннары, авыл-шәһәр исемнәре татарча әйтелешендә биреләләр. Шунлыктан Тобольск түгел,— Тубыл; Тетюши түгел,— Тәтеш; Чистопольск түгел,— Чистай; Бирск түгел,— Бөре; Тав-лина түгел,— Тау иле; Агрыз түгел,— Әгерҗе, Астрахань түгел,— Әстерхан; Учалинск түгел,— Ачулы; Челябинск түгел,— Чиләбе, Саратов түгел,— Саратау һ. б. Мондый исемнәрнең татарча язылышлары шул җирләрнең тарихын да күрсәтеп торалар. Әйтик, «Уфа»ның «Өфе» булуы аның шәһәр исеме генә түгел, меңнәрчә чакрымга сузылган Өфе елгасы тамагы 'булуы белән дә бәйләнгән. Ул, иске «Тәвәрихе Болгария»дә, «Болгар юлы» бәетләрендә «Өфе буе» дип телгә алынган кебек, соңгы якта классигыбыз Г. Камалның «Бәхетсез егет»ендә дә «Өфе» дип языла. Шуның кебек исемнәр татар һәм башкортның бу җирләрдә төп халыклар булуын һәм ватанчылыгын күрсәтеп торганга, үз әйтелешләре буенча язылышлары, әлбәттә, сакланырга тиеш.

«Кимә» (.каек) сүзе бездә гөмбәз яки русчадагы ки бит к а мәгънәләрендәге «көймә» сүзе белән 'бертөсле язылып йөртелүе, әлбәттә, хата. Ул сүзләр элекке әдәби телебездә, халык телендә сөйләшкәнчә, ике төрле языла иде. Хәзерге 'бу хата бигрәк тә табышмак табучының зиһенен чуалтуга сәбәп булганга, текстларда урынына карап «кимә» һәм «көймә» рәвешендә язылды. Кара исәп-хисап табышмакларында укучы яшьләргә үз инициативаларына юл бирү өчен кайбер мәсьәләләргә аңлы рәвештә җавап бирелмичә калдырылды.

Сүз ахырында шунысы да әйтелергә тиеш: кереш мәкаләдә бу язганнарым башта табышмаклар өстендә озак еллар һәм кат-кат эш иткәндә практикада туган кайбер уйлар !һәм вак кәгазь кисәкләренә сызгалап барган күзәтмәләрем иде. Шулардай берхәтлесен

TURKISTAN KUTUBXONASI - ТУРКЕСТАНСКАЯ БИБЛИОТЕКА

бүлекләп тер-кәгәч, шушындый зур гына мәкалә булып китте. Минем >бу мәкаләм нинди дә булса гыйльми китапларга таянып язылган теория яки гомумиләштерелгән гыйльми бер трактат түгел икәнлеге шуңардан аңлашылса кирәк. Чөнки бит һәрбер язучының нинди дә булса үзен кызыксындырган берәр мәсьәләгә карата үз язмалары була. Мин бу язылганнарга бары тик «Табышмаклар өстендә минем эзләнүләрем» дип кенә карыйм. Шулай булгач, хөрмәтле укучыларым да алар-га «язучы язмалары» итеп карарлар, ә инде гомуми теорияләргә сыеп бетмәгән урыннарын минем шәхси карашыма кайтарып калдырырлар, ә, бәлки, яңа эзләнүләр өчен үзләренә кайбер «җап очы» да табарлар һә,м кимчелекләрен төзәтешергә ярдәм итәрләр дигән өметтә калам.

*НӘКЫЙ ИСӘНБӘТ. Ноябрь, 1967 ел, Казан.*

## Татар халык табышмаклары

**I бүлек.**

**Аң-белем, әдәбият, уку-язу, хат-хәбәрләшү**

* Акыллыга да әйттем –
Уйлады да белде;
Акылсызга да әйттем –
Тыңлады да көлде.
(*Табышмак*)

* Югалткан әйберең түгел, –
Эзләмичә тапмыйсың.
(*Табышмак*)

* Әйткәч, беләсегез килә,
Белгәч, көләсегез килә.
(*Табышмак*)

* Утыз тештән чыккан – утыз адәмгә җәелә.
(*Мәкаль*)

* Моны миңа сөйләде Алдар,
Әгәр сиңа очраса,
Ул сине дә алдар;
Болар барсы да ялган,
Ялган булса да,
Ак кәгазьгә язылган.
(*Әкият*)

* Үлчәүләрдә үлчәнми,
Базарларда сатылмый.
(*Акыл*)

TURKISTAN KUTUBXONASI - ТУРКЕСТАНСКАЯ БИБЛИОТЕКА

* Аршынлы түгел, потлы түгел,
Һәркемдә бар.
(*Акыл*)

* Бер байлык бар – янмый,
Карак та урлый алмый,
Төшеп тә югалмый.
(*Белем*)

* Акыллы чәчә барыр,
Акылсыз җыя барыр.
(*Белем*)

* Ачыдан ачырак, татлыдан татлырак,
Усалдан усалрак, дөрестән дөресрәк
Нәрсә бар дөньяда?
(*Тел*)

* Акчасыз керәсең, хәзинә алып чыгасың.
(*Мәктәп*)

* Агач түгел – яфраклы,
Тун түгел – тегелгән.
(*Китап*)

* Кабат-кабат катлама,
Акылың булса ташлама.
(*Китап*)

* Теле юк – үзе аңлата.
(*Китап*)

* Анда бар да бар.
(*Китап*)

* Өнсез, җансыз – иң якын дус.
(*Китап*)

* Кечкенә генә сандыкка бөтен дөнья сыйган.
(*Китап*)

* Ак җир, кара тап,
Нәрсә булыр, уйлап тап.
(*Китап*)

* Ак ялан, кара сукмак, –
Йөри белгән эз табар.
(*Китап*)

TURKISTAN KUTUBXONASI - ТУРКЕСТАНСКАЯ БИБЛИОТЕКА

* Ача да яба, ача да яба,
Җавабын зирәк таба.
(*Китап*)

* Киштә башында төпле төргәк,
Аңа һәр өйдә хөрмәт,
Һәркемгә дә иң кирәк.
(*Китап*)

* Кул белән чәчәсең, күз белән җыясың.
(*Язу*, *уку*)

* Җирлеге ак, орлыгы кара,
Җимеше ни булыр? –
Тикшереп кара.
(*Кәгазь*, *юзу*, *уку*)

* Кәкре-бөкре сызылган,
Хәрефләре сыгылган,
Асты бар, өсте бар,
Тырма кебек теше бар.
(Язу)

* Аш ашамас,
Кара су эчәр,
Дөньяда кош кебек очар,
Күңелләргә нур чәчәр.
(*Язу*)

* Җир өстендә күп кешеләр
Кар өстенә кара солы чәчәләр.
(*Язу*)

* Бишәү чәчә, берәү җыя.
(*Язу*, *уку*)

* Иген чәчте биш малай,
Урдылар ике агай.
(*Язу*, *уку*)

* Кул белән чәчәсең,
Күз белән җыясың.
(*Язу*, *уку*)

* Җире ак, орлыгы кара,
Кул белән чәчәләр,
Авыз белән җыялар.
(*Кәгазь*, *язу*, *уку*)

TURKISTAN KUTUBXONASI - ТУРКЕСТАНСКАЯ БИБЛИОТЕКА

* Ак ялан,
Ак яланда эз калган,
Эз өстендә күз калган.
(*Кәгазь, язу, уку*)

* Җаны юк, үзе кырык төрле тел белә.
(*Каләм*)

* Үзе укырга белмәсә дә гомер буе язына.
(*Каләм*)

* Кәгазь өстен карайта,
Дөнья йөзен агарта.
(*Каләм*)

* Үзе бер карыш,
Теле мең карыш.
(*Каләм*)

* Үзе йөзә – чылбыр тезә.
(*Каләм*)

* Авызы бер, теле ике, җаны юк.
Сөйләгән сүзенең һич саны юк.
(*Каләм*)

* Менә табышмак, уйлап кара:
Суы тәмсез, йөзе кара,
Чиләгенең төбе юк,
Файдасының чиге юк.
(*Кара һәм кара савыты*)

* Кара кыр буйлап ак куян чаба.
(*Кара такта, акбур*)

* Бер чыгарып җибәрсәң,
Нихәтле чакырсаң да кире кайтмый.
(*Сүз*)

* Әйтермен – миннән китәр,
Тыңламасаң – синнән китәр.
(*Сүз*)

* Сөрмәгән җирдә тумаган куян баласы.
(*Ялган сүз*)

* Диңгезе бар, суы юк,
Каласы бар, халкы юк,
Урманы бар, агачы юк.
(*Карта*)

TURKISTAN KUTUBXONASI - ТУРКЕСТАНСКАЯ БИБЛИОТЕКА

* Шәһәрләр – йортсыз,
Диңгезләр – сусыз.
(*География картасы*)

* Ямавы бар, җөе юк,
Каласы бар, өе юк.
(*Карта*)

* Бабай бүреге йөз ямау.
(*Глобус*)

* Аягы юк – китәр,
Җибәргән җиргә җитәр,
Кушкан йомышны үтәр.
(*Хат*)

* Теле юк, теләсә кем белән сөйләшә,
Гәүдәсе юк, кәгазьдән күлмәк кия.
(*Хат*)

* Дүрт почмаклы келәтем, –
Аккошым бар эчендә;
Кеше алыр дип кайгым юк, –
Тамгасы бар түшендә.
(*Хат*)

* Кабат-кабат,
Бер кошта өч йөз алтмыш биш канат,
Мин торам аны санап,
Көн дә кими бер канат.
(*Календарь*)

* Күңелсезгә – юаныч,
Күңеллегә – куаныч.
(*Җыр*)

**II бүлек.**

**Табигать күренешләре, ел фасыллары**

* Өй башына утырган,
Җир йөзен нуры белән тутырган.
(*Кояш*)

* Ул булса, көн була.
Ул булмаса, төн була.
(*Кояш*)

TURKISTAN KUTUBXONASI - ТУРКЕСТАНСКАЯ БИБЛИОТЕКА

* Лампа түгел – яктырта,
Мич түгел – җылыта.
(*Кояш*)

* Тау башында җәүһәр таш,
Аңа туры караган кешенең күзе яшь,
Аны тапкан кешегә йөз егерме яшь.
(*Кояш*)

* Егет егетлеген итә,
Елмаеп боз эретә.
(*Кояш*)

* Зур палас,
Төбендә – йомры калач.
(*Күк, ай*)

* Нәрсә төнне яктырта,
Нәрсә яна – яндырмый?
(*Кояш, ай*)

* Иртән чыга,
Кичен югала,
Аның урынына
Энесе кала.
(*Кояш, ай*)

* Алтын китте, көмеш килде.
(*Кояш, ай*)

* Өй өстендә ярты күмәч.
(*Ай*)

* Үзе урак, үзенең теше юк.
(*Ай*)

* Өй артында – ак калач.
(*Ай*)

* Төнлә калка, көндез ята.
(*Ай*)

* Мич тулы пәрәмәч,
Уртасында – бер калач.
(*Ай, йолдызлар*)

* Мең шырпыга бер лампа.
(*Ай*)

TURKISTAN KUTUBXONASI - ТУРКЕСТАНСКАЯ БИБЛИОТЕКА

* Ярты телем ипи
Бөтен дөньяга җиткән.
(*Ай*)

* Бер көтүче мең сарык көтә.
(*Ай, йолдызлар*)

* Бер атасы, бер анасы,
Ничә йөз мең баласы.
(*Кояш, ай һәм йолдызлар*)

* Атамның бер туны бар.
Ябынып булмый;
Эче тулы ак энҗе,
Санап булмый.
(*Күк һәм йолдызлар*)

* Кич булганда күренер,
Таң булдымы – күмелер.
(*Йолдыз*)

* Актыр үзе, югары,
Җем-җем итеп ул тора;
Бүген таңда килмәсәң.
Китәмен дип утыра.
(*Йолдыз*)

* Өй түбәмдә – җиз кадак.
(*Йолдыз*)

* Үзе ялтырый, үзе калтырый.
(*Йолдыз*)

* Ай белән килә,
Көн белән китә,
Алтын башлы,
Көмеш чәчле,
Мең дә бер йәшле.
(*Йолдыз*)

* Вак кынадыр үзләре,
Ялтырыйдыр күзләре.
(Йолдызлар)

* Күл тулы алтын балык.
(*Йолдызлар*)

* Өй башында – җиз иләк.
(*Йолдызлар*)

TURKISTAN KUTUBXONASI - ТУРКЕСТАНСКАЯ БИБЛИОТЕКА

* Төнлә баксам, күк тулган,
Иртән баксам, юк булган.
(*Йолдызлар*)

* Атайдан калган зур коштабак,
Коштабак тулы җиз кадак.
(*Йолдызлар*)

* Җәүһәр сиптем, җиргә төшми,
Алыйм дисәм, буем җитми.
(*Йолдызлар*)

* Берсе чәчә, берсе эчә, берсе үсә.
(*Болыт*, *җир*, *үлән*)

* Ишектән керер, түргә менеп утырыр.
(*Суык*)

* Аяксыз-кулсыз рәсем ясый.
(*Суык*)

* Аягы юк, кулы юк,
Тәрәзәгә гөл ясый.
(*Суык*)

* Үзе шушында, үзе беленми;
Тынга беленә, күзгә күренми.
(*Һава*)

* Ипи түгел, су түгел,
Авыр түгел, аз түгел,
Ансыз яшәү мөмкин түгел.
(*Һава*)

* Аягы юк - качадыр, канаты юк - очадыр.
(*Төтен*)

* Мич эчендә кара мәче.
(*Төтен*)

* Алтын капка ябыла,
Көмеш капка ачыла,
Мәрди бабай кычкыра,
Үлгән кеше терелә.
(*Кояш чыга*, *ай бата*, *әтәч кычкыра*, *кешеләр йокыдан тора*)

* Тау аркылы ук аттым,
Аткан угым югалттым.
(*Йолдыз атылу*)

* Сыр-сыр сыры бар,
Алты төрле нуры бар,
Җиде кат күккә юлы бар.
(*Салават күпере*)

* Урманда урынсыз,
Кырда койрыксыз.
(*Җил*)

* Кулсыз-аяксыз тәрәзә кага.
(*Җил*)

* Аягы юк, кулы юк,
Сөйләшергә теле юк,
Кояш кебек нуры юк,
Күрергә күзе юк,
Һич җитмәгән җире юк.
(*Җил*)

* Үзе ямьсез ыжгыра,
Кар буранын туздыра.
(*Буран*)

* Йон түшәгем ертылды,
Бөтен дөнья йон булды.
(*Буран*)

* Котыра да үкерә,
Бөтен җирне тутыра.
(*Буран*)

* У-у, улыйдыр,
Йоннан бура бурыйдыр,
Койма белән урыйдыр.
(*Буран*)

* Кышын ята таштай,
Язын чаба аттай.
(*Боз*)

* Көзен туа, язын үлә.
(*Боз*)

* Утта янмый,
Суда батмый.
(*Боз*)

* Тышка куйдым – таш булды,
Өйгә керттем – су булды.
Инде нихәл итәем,

TURKISTAN KUTUBXONASI - ТУРКЕСТАНСКАЯ БИБЛИОТЕКА

Утка куйсам – бу булды.
(*Боз*)

* Мамык юрган,
Кат-кат сырган,
Үзе суп-суык.
(*Кар*)

* Менә ята җәүһәр таш,
Алыйм дисәң, юк була.
(*Кар*)

* Элек үзе судан туды,
Хәзер үзе су тудыра;
Ак мамык кебек,
Ялтырый алмаз кебек.
(*Кар*)

* Ак ябалак ак киезгә ятыр.
(*Кар*)

* Мамык түшәгем
Җиргә түшәдем.
(*Кар*)

* Ак ашъяулык таптык,
Җир өстенә яптык.
(*Кар*)

* Канатсыз оча,
Аяксыз чаба.
Тышта өелә,
Өйдә җәелә.
(*Кар*)

* Ятты-ятты да елгага карап чапты.
(*Кар*)

* Суык булса тик ята,
Һичбер сүз дәшми,
Каты салкын кышларда да
Сабыр итә.
Яз башында көн җылынгач
Йөгерә башлый,
Бик эсседә канатлана,
Очып китә.
(*Кар*)

* Чит-чите – таллык,
Уртасы – сазлык;

TURKISTAN KUTUBXONASI - ТУРКЕСТАНСКАЯ БИБЛИОТЕКА

Керсәң – батарсың,
Чыгалмый ятарсың.
(*Күл*)

* Башы тауда, аягы диңгездә.
(*Елга*)

* Сорыйлар, көтәләр, килсәм бар да качалар.
(*Яңгыр*)

* Күктән килде, җиргә китте.
(*Яңгыр*)

* Ялт-йолт ялтырый,
Җирнең өсте калтырый,
Энҗе кебек тезелә,
Ефәк кебек сузыла.
(*Яшен, яңгыр*)

* Атамның бер туны бар, –
Ябынып булмый;
Эче тулы ак энҗе, –
Санап булмый.
(*Күк һәм йолдызлар*)

* Зур палас төбендә йомры калач.
(*Күк һәм ай*)

* Төнлә баксам – күк тулган,
Иртән баксам – юк булган.
(*Йолдызлар*)

* Мең тәңкә, уртасында бер тәңкә.
(*Ай һәм йолдызлар*)

* Елмый агай елмаеп боз эретә.
(*Кояш*)

* Шундый зур – бөтен җирне әйләндереп ала,
Шундый кечкенә – иң кечкенә ярыкка да сыя.
(*Җил-давыл*)

* Үзе күренми, үзе сызгыра,
Үзе бар нәрсәне пыр туздыра.
(*Җил-давыл*)

* Тәрәзәдән сыя, –
Ишектән сыймый,
Сандыкка сыя, –

TURKISTAN KUTUBXONASI - ТУРКЕСТАНСКАЯ БИБЛИОТЕКА

Салып бикләп булмый.
(*Кояш нуры*)

* Өй артында озын агай
Энә белән кое казый.
(*Тамчы*)

* Үзе туңа, өйгә керми,
Үзе җылый да җылый.
(*Тамчы*)

* Аяксыз-кулсыз дөп-дөп кое казый.
(*Тамчы*)

* Үзе туңа, үзе керми,
Үзе елый да елый.
(*Кәрнизгә каткан боз сөңгесе*)

* Өй артында ак тана
Мөгезем бар дип мактана.
(*Боз сөңгесе*)

* Тәнсез тора, телсез сөйләшә,
Һичкем аны күрми, һәркем аны ишетә.
(*Кайтаваз*)

* Сөйләгәнне үзеңә кайтара. Ул нәрсә?
(*Яңгыравык, кайтаваз*)

* Бабай килгән сагынып,
Ак чикмәнен ябынып.
(*Кыш килү*)

* Ала-сыер ятып кала,
Ак сыер торып китә.
(*Яз*)

* Ак сыер – торыйк, ди,
Кара сыер – ятыйк, ди.
(*Яз көне кар белән җир*)

* Кигән киеменең бизәге
Бөтен дөньяны ямьгә бизәде.
(*Җәй*)

* Аты юк, тәртәсе юк,
Көне-төне бара, юлы кала.
(*Елга, чишмә*)

TURKISTAN KUTUBXONASI - ТУРКЕСТАНСКАЯ БИБЛИОТЕКА

* Аты бара, тәртәсе кала.
(*Елга белән яр*)

* Уты юк, төтене бар.
(*Томан*)

* Көн туганчы көн итә,
Үлән башын су итә.
(*Томан*)

* Тау куенында анасы,
Чыгып кача баласы.
(*Чишмә*)

* Төнлә тәрәзәсе биклэнә,
Көндез ачыла.
(*Бәке*)

* Сыр-сыр сыргалан,
Уртасында бер табак.
(*Бәке*)

* Торналар торып китте,
Агыйдел агып калды.
(*Боз китү, елга ачылу*)

* Кара куйның тиресен әйләндереп капладым.
(*Игенчелек*)

* Диңгез түгел – дулкынлана.
(*Иген кыры*)

**III бүлек.**
**Үсемлекләр, куаклар, агачлар**

* Язын ямь бирә,
Җәй салкын бирә,
Көзен тәм бирә,
Кышын тун бирә.
(*Урман*)

* Җәй киенә, кыш чишенеп ташлый.
(*Урман*)

* Төбе бер, башы мең.
(*Агач*)

* Яз килсә – киенә,
Көз килсә – чишенә.
(*Агач*)

* Җәй дә егет, кыш та егет,
Картайганы юк, гел егет.
(*Чыршы*, *нарат*)

* Бәләкәй генә бер чүлмәк,
Авызы-җөе күренми.
Ничек кенә йөртсәң дә,
Ашы һичбер түгелми.
(*Чикләвек*)

* Утта яна,
Суда батмый.
(*Агач*)

* Кайчысыз киселә,
Җепсез тегелә.
(*Яфрак*)

* Язын дөньяга килә,
Көзен саргаеп үлә.
(*Яфрак*)

* Үзе аяксыз-кулсыз,
Сикерә дә төшә, сикерә дә төшә.
(*Яфрак*)

* Иелә, бөгелә,
Ак мамыгы түгелә,
Кара күзе күренә.
(*Шомырт*)

* Нинди агач җилсез шаулый?
(*Усак*)

* Аягы алтмыш,
Кулы җитмеш,
Бите мең бер йөз җитмеш.
(*Тирәк*)

* Җәй дә, кыш та бер төстә.
(*Чыршы*)

* Җәй дә, кыш та, яз да, көз дә
Чәчәк ата бер төстә.
(*Чыршы*)

TURKISTAN KUTUBXONASI - ТУРКЕСТАНСКАЯ БИБЛИОТЕКА

* Яфрак та түгел,
Ботак та түгел,
Үзе агачта үсә.
(*Агач кайрысы*)

* Эчен ашыйлар,
Тышын ташлыйлар.
(*Чикләвек*)

* Кат-кат,
Катлы сарай эчендә
Падишаның бер кызы бар,
Бикле сарай эчендә.
(*Чикләвек*)

* Бәләкәй генә бер чүлмәк,
Авызы, җөе күренми,
Ничек кенә йөртсәң дә,
Ашы мичтә түгелми.
(*Чикләвек*)

* Ак яулыклар ябынган,
Ал кыналар ягынган;
Кулым сузсам – тешләп алды,
Шул кадәрле сагынган.
(*Гөлҗимеш*)

* Бабай мескен картайган,
Эшләпәсе янтайган
(*Көнбагыш*)

* Гәүдәсе нәзек булса да,
Бик зур чалма чорнаган.
(*Көнбагыш*)

* Озын буйлы, зәңгәр күзле.
(*Җитен*)

* Аягында кара ката,
Тәпиеңдә кызыл оек,
Яшел күлмәкле, ак яулыклы.
(*Карабодай*)

* Бер үлән бар чокырда,
Аны таный сукыр да.
(*Кычыткан*)

* Кыйнамый, сукмый, үзе елата.
(*Кычыткан*)

TURKISTAN KUTUBXONASI - ТУРКЕСТАНСКАЯ БИБЛИОТЕКА

* Җаны булмаса да, гомер итә.
(*Үсемлек*)

* Язын дөньяга килә,
Көзен саргаеп үлә.
(*Яфрак*)

* Аягы суда, башы көндә.
(*Төнбоек*)

* Олысы да, кечесе дә эшләпә кигән.
(*Гөмбә*)

**IV бүлек.**
**Бөҗәкләр, кошлар, җәнлекләр, йорт хайваннары**

* Ала чапан киенгән,
Мал суйганга сөенгән,
Шунда төшеп йөгергән.
(*Саескан*)

* Савытыннан сабы озын.
(*Саескан*)

* Кечкенә генә берәү,
Артында озын тераү.
(*Саескан*)

* Аягы кулдан югары,
Сикерә талдан югары;
Ни кош түгел, ни корт түгел,
Тезе билдән югары.
(*Чикерткә*)

* Кырда кара казаным кайный.
(*Кырмыска оясы*)

* Җаны бар да каны юк,
Йөк тартырлык хәле юк.
(*Чебен*)

* Колга башында бер өй,
Кунагым тәрәзәсеннән йөри.
(*Сыерчык оясы һәм сыерчык*)

TURKISTAN KUTUBXONASI - ТУРКЕСТАНСКАЯ БИБЛИОТЕКА

* Колга башыңда йорты,
Эчендә аның җырчы.
(*Сыерчык*)

* Бер кошым бар: тынмый,
Агачка оя кормый;
Ое-җирдә,
Җыры – күктә.
(Тургай)

* Кулы юк, балчык ташый,
Балтасы юк, өй ясый.
(*Карлыгач*)

* Гөлдер-гөлдер гөл итекле,
Гөлкәй кызыл читекле.
(*Күгәрчен*)

* Җәй такылдый бу чүкеч,
Кыш такылдый бу чүкеч.
Ничек чыдый бу чүкеч?
(*Тукран*)

* Агач башында бәйле букча.
(*Кош оясы*)

* Бер җәнлек үзенә тарта,
Берсе читкә ыргыта.
(*Тавык*)

* Сакаллы килеш туа, берәү дә гаҗәпләнми.
(*Кәҗә*)

* Кабара, кабара, кабара күк,
Кабарып пешкән икмәк күк;
Шыгай улы кунак күк,
Киенеп чыккан кияү күк.
(*Күркә*)

* Тимерче дә түгел,
Балта остасы да түгел,
Үзе авылда беренче эшче.
(*Ат*)

* Калын арка,
Тарта да тарта,
Ул тарткан саен табыш арта.
(*Ат*)

TURKISTAN KUTUBXONASI - ТУРКЕСТАНСКАЯ БИБЛИОТЕКА

* Дүрттер аның аягы,
Түбәсендә колагы;
Илдән-илгә җиткерер,
Таштан каты тоягы.
(*Ат*)

* Койрыгы салпы,
Ике колагы кайчы,
Аны белмәгәннең сыртына –
каеш камчы.
(*Ат*)

* Безнең өч дусыбыз бар:
Берсе ашата,
Икенчесе эчертә,
Өченчесе йорт саклый.
(*Ат, сыер, эт*)

* Үлән ашый, май ташый.
(*Сыер*)

* Койрыгыннан мөгезе озын.
(*Кәҗә*)

* Сакалы бар, акылы юк.
(*Кәҗә*)

* Ни, сакаллы булып, карт түгел,
Ни, мөгезле булып, үгез түгел,
Ни, мамыклы булып, кош түгел,
Ни, үзе юкә суйса да, чабата ясамый.
(*Кәҗә*)

* Бар бездә сакаллы бер түрә,
Бакчалары күп аның, –
Берсеннән чыга, берсенә керә.
(*Кәҗә*)

* Юк үзенең әдәбе,
Маңгаенда сәнәге,
Көелып йөри сәдәбе.
(*Кәҗә*)

* Бәләкәй генә буйлы,
Әйләндереп кигән тунлы.
(*Сарык*)

* Ашата, туендыра,
Җылыта, киендерә,

TURKISTAN KUTUBXONASI - ТУРКЕСТАНСКАЯ БИБЛИОТЕКА

Кешене сөендерә.
(*Сарык*)

* Кечкенә генә татар,
Язын тунын сатар.
(*Сарык*)

* Ачмаган сандык эчендә текмәгән туным ята.
(*Сарык бәрәне*)

* Ияре дә, дугасы да үзендә.
(*Дөя*)

* Бүре түгел - көрән,
Куян түгел – озын колаклы,
Ат түгел – тояклы.
(*Ишәк*)

* Төрән танау җир сөрә.
(*Дуңгыз*)

* Мыр-мыр мырлысы, бик каты икән борнысы.
(*Дуңгыз*)

* Кешенең дусты, йортның сакчысы.
(*Эт*)

* Сакбаем теле сынып төшсә дә, койрыгы югары.
(*Эт*)

* Йөгерә-йөгерә дә балта сабы өстенә утыра.
(*Эт*)

* Мыегы бар, сакалы юк,
Туны бар, чапаны юк;
Файдасы өйдә булгач,
Яланга сәфәре юк.
(*Мәче*)

* Үзе мич башында,
Үзе тун ябынып йоклый.
(*Мәче*)

* Берсе өйне саклый,
Берсе тышны саклый,
Үзләре бер-берсенә кан дошманы.
(*Мәче һәм эт*)

* Сөяк авыз, ит сакал.
(*Әтәч*)

TURKISTAN KUTUBXONASI - ТУРКЕСТАНСКАЯ БИБЛИОТЕКА

* Башы тарак, койрыгы урак.
(*Әтәч*)

* Йөгерде-йөгерде,
Җиренә җиткәч утырды.
(*Тавык*)

* Канаты бар,
Аягы бар, –
Йөзә алмый.
(*Тавык*)

* Кечкенә генә кодача,
Итәкләрен җил ача.
(*Тавык*)

* Безнең киленнең кырык итәге,
Урамга чыкса, җил кайтара.
(*Тавык*)

* Яшел палас өстендә сары йомгак тәгәри.
(*Каз бәбкәсе*)

* Йомры, йомшак сары йомгак
Йөгереп йөри чирәмдә.
(*Чеби*)

* Йон йомгагым – бөдерә,
Су күрдеме – йөгерә.
(*Үрдәк бәбкәсе*)

* Суда юынып алды,
Өсте коры калды.
(*Каз*)

* Суда йөзә,
Күктә оча,
Җирдә йөри.
Ит белән сыйлый.
(*Каз*)

* Су төбенә төшә,
Чыланмыйча чыга.
(*Үрдәк*)

* Кырда йөрсә – кыр киеге,
Суда йөзсә – су киеге.
(*Үрдәк*)

* Мыегы бар, сакалы юк,
Туны бар, чапаны юк;
Файдасы өйдә булгач,
Яланга сәфәре юк.
(*Мәче*)

* Аягын-башын яшерә таш күлмәге эченә.
(*Ташбака*)

* Җәйнең буе бал җыя,
Кышның буе хәл җыя.
(*Бал корты*)

* Тимәгәнгә тимим,
Тигәнне җавапсыз калдырмыйм.
(*Бал корты*)

* Канаты бар, каны юк.
(*Күбәләк*)

* Кем үз өясы өстендә йөри?
(*Әкәм-төкәм*)

* Күрер-күрмәс күзләре,
Челтәр бәйли үзләре;
Челтәрләре түгәрәк,
Эшли алар үрмәләп.
(*Үрмәкүч, пәрәвез*)

**V бүлек.**
**Яшелчә, җиләк-җимеш**

* Үскәндә яфрагын ашыйлар,
Үсеп җиткәч, тамырын ашыйлар.
(*Суган*)

* Ачыдыр теле, кыллыдыр төбе.
(*Суган*)

* Кечкенә генә сары карт,-
Кигән туны тугыз кат.
(*Суган*)

* Үзем туныйм, үзем елыйм да елыйм.
(*Суган*)

TURKISTAN KUTUBXONASI - ТУРКЕСТАНСКАЯ БИБЛИОТЕКА

* Бер кисмәктә мең егет.
(*Кыяр*)

* Тәрәзәсе юк, ишеге юк,
Эче тулы халык.
(*Кыяр*)

* Кечкенә генә йорт,
Эче тулы корт.
(*Кыяр*)

* Ишеге-тәрәзәсе юк,
Өй эче тулы кунаклар.
(*Кыяр*)

* Җир астында алтын казык.
(*Кишер*)

* Кызыл кызы җир эчендә,
Чәчләре җир өстендә.
(*Кишер*)

* Үзе кызыл, үзе буямаган.
(*Кишер*)

* Кызыл кызы җир өстендә,
Чәчләре җир өстендә.
(*Кишер*)

* Үзе – бер бөртек, эче – мең бөртек,
Башы – җирдә, койрыгы – коймада.
(*Кабак*)

* Бер күтәрәм йорт,
Эче тулы яссы корт.
(*Кабак*)

* Келәте бар, малы юк,
Баласының саны юк.
(*Кабак*)

* Эсселәгән саен,
Кат-кат тун кия.
(*Кәбестә*)

* Утыра бер ак чүлмәк,
Өстенә кигән йөз күлмәк.
(*Кәбестә*)

TURKISTAN KUTUBXONASI - ТУРКЕСТАНСКАЯ БИБЛИОТЕКА

* Аяксыз-кулсыз, мең кат кигән.
(*Кәбестә*)

* Үзе шардай, эче кандай, тәме балдай.
(*Карбыз*)

* Эче кызыл шикәрле,
Тышы яшел бәрхетле.
(*Карбыз*)

* Яшел сарай эчендә
Кызыл бояр утыра.
(*Карбыз*)

* Үзе кып-кызыл,
Күлмәге ям-яшел.
(*Карбыз*)

* Җир астында җиз бүкән, –
Ул ни икән?
(*Бәрәңге*)

* Чәчәге агачында,
Алмасы тамырында.
(*Бәрәңге*)

* Төбе алмалы,
Башы чалмалы.
(Бәрәңге)

* Җир астында җиз бүкән.
(*Торма*)

* Түгәрәк кенә кызыл йорт,
Эче тулы корт.
(*Помидор*)

* Түгәрәк – ай түгел,
Сары – май түгел,
Койрыгы бар – тычкан түгел.
(*Шалкан*)

* Җир астында картыгыз,
Сакалыннан тартыгыз.
(*Шалкан*)

* Гәүдәсе бар – җаны юк,
Үзе эшләпә кигән – башы юк.
(*Гөмбә*)

TURKISTAN KUTUBXONASI - ТУРКЕСТАНСКАЯ БИБЛИОТЕКА

* Бикле келәт эчендә кара ком.
(*Мәк*)

* Бер ботак,
Бер ботакта бер мең борчак.
(*Мәк*)

* Таяк,
Таяк өстендә маяк;
Маяк өстендә кибет,
Кибет эчендә дүрт мең егет.
(*Мәк*)

**VI бүлек.**
**Кыргый хайваннар, җәнлекләр, киек-кош**

* Сорыдыр төсе,
Үткендер теше,
Урманда йөри,
Сарыклар эзли.
(*Бүре*)

* Асрамый да умарта,
Балны бик-бик ярата.
Кышын сөя йокыны,
Язгача тормый ята.
(*Аю*)

* Җәен урманга патша,
Кышын кардан да аста.
(*Аю*)

* Урманнан чыгар, корсак асты чуар;
Койрыгы сырлы, хәйләсе күптөрле.
(*Төлке*)

* Нечкә билле, көлтә койрыклы.
(*Төлке*)

* Әдәпле генә кодача
Тавыкларны ярата.
(Төлке)

* Бер йомгакта мең энә,
Сиңа тими, син тимә.
(*Керпе*)

* Яланда энәле йомгак ятыр.
(*Керпе*)

* Энәләре үзе белән йөри,
Үзе тегә белми.
(*Керпе*)

* Өстенә шау энәле күлмәк кия,
Шулай да аны әнисе "йомшагым" дип сөя.
(*Керпе*)

* Йомры-йомры туп кебек,
Бөтен тәне шырт кебек.
(*Керпе*)

* Бәләкәй генә карчык,
Тәне тулы шырпы.
(*Керпе*)

* Әлем, әлем, әлем күк,
Бөгәрләнгән мәче күк;
Аны кеше тоталмый,
Тәпиләрен кūралмый.
(*Керпе*)

* Җиз камчысын тотып булмый,
Җиз атына утырып булмый.
(*Елан һәм бүре*)

* Әнә бара хан,
Авызы-борыны кан.
(*Бүре*)

* Җәен соры, кышын ак,
Аңа шулай яхшырак.
(*Куян*)

* Урманнан чыгар, үзе чабар.
(*Куян*)

* Әйтим бер йомак:
Җәен соры, кышын ак,
Төймә койрык, шеш колак.
(*Куян*)

* Аягын-башын яшерә
Таш күлмәге эченә.
(*Ташбака*)

* Озын эчәк,
Бер очы төенчек.
(*Елан*)

* Югары менә чылбырсыз,
Түбән төшә баскычсыз,
Өйләр сала балтасыз.
(*Кош*)

* Төнлә йөрергә ярата,
Көндез йөрми, йокыга ята.
(*Ярканат*)

* Ияре дә, дугасы да үзендә.
(*Дөя*)

* Чылт-чылт күзле,
Адәм төсле йөзле,
Үчекләшер үзе,
Ходайның боерыгы,
Бардыр койрыгы.
(*Маймыл*)

* Җәй буе акыл сата,
Кышын боз булып ката.
(*Бака*)

* Кош түгел, оча,
Ябалактан курка,
Чикләвекне ярата,
Сызгырса, урманны яңрата.
(*Тиен*)

* Җир астында җирән атым,
Яр астында бурлы атым.
(*Тычкан, балык*)

* Койрыгы озын,
Үзе кыска,
Мәчедән курка.
(*Тычкан*)

* Кечкенә генә йомры шар,
Аннан явыз нәрсә бар?
(*Тычкан*)

* Эргәдәдер өйләре,
Бал-май ашар үзләре,
Елт-елт итәр күзләре.
(*Тычкан*)

TURKISTAN KUTUBXONASI - ТУРКЕСТАНСКАЯ БИБЛИОТЕКА

* Койрыгы бар – бутый алмый,
Аягы бар – йөри алмый.
(*Ярканат*)

* Канаты бар – очмыйдыр,
Күккә карамыйдыр,
Аяклары юк – йөридер,
Җирдә тормыйдыр,
Кешеләрне белмидер.
(*Балык*)

* Канаты бар – очалмый,
Күккә таба карамый,
Йолдызларны да санамый,
Коры җирдә торалмый.
(*Балык*)

* Башы бар, чәче юк,
Күзе бар, кашы юк.
Авызы бар, теле юк.
Гәүдәсе бар, муены юк,
Суыкта туңмый,
Эсседә көйми,
Аягы юк, үзе йөри.
(*Балык*)

* Яр астыннан яу уза, –
Кылычлы да мылтыклы.
(*Балык*)

* Урманнан чыгар,
Койрык асты чуар,
Түше белән шуар,
Кеше күрсә – куар,
Алты аяклы,
Алтын сыртлы.
(*Елан*)

**VII бүлек.**
**Йорт, каралты-кура, өй җиһазлары, эш кораллары, савыт-саба, ашау-эчү, ризыклар, кием-салым, транспорт чаралары**

* Түбән өйдә дүрт бүре,
Дүртесе дә күк бүре.
(*Өй нигезе, почмаклары*)

* Йомрыдыр тыштан,
Эчке ягы ешкан,

TURKISTAN KUTUBXONASI - ТУРКЕСТАНСКАЯ БИБЛИОТЕКА

Осталар шулай кушкан.
(*Стена бүрәнәсе*)

* Тышта санадым – сигез,
Өйдә санадым – дүрт.
(*Өй почмаклары*)

* Ишектән кергән дә сузылып яткан.
(*Идән*)

* Гәүдәсе өйдә,
Башы тышта.
(*Матча*)

* Атасы аркылы яткан,
Балалары буй яткан.
(*Түшәм*)

* Бер патша мең патшаны баш идергән.
(*Ишек*)

* Кулын бирә,
Кулың кысмый.
(*Ишек тоткасы*)

* Аяксыз-кулсыз өй саклый.
(*Йозак*)

* Кечкенә генә эт,
Өрми дә, җибәрми дә.
(*Йозак*)

* Йорт каравылчысы – бөкере карчык.
(*Йозак*)

* Эт түгел – өрми,
Кеше түгел – йөрми,
Өйгә кеше кертми.
(*Йозак*)

* Юаш ятар,
Дәшми тотар.
(*Капкын*)

* Акылы юк, ә хәйләкәр.
(*Капкын, тозак*)

* Берсе:"Акны яратам", – ди,
Берсе:"Караны яратам", – ди,

TURKISTAN KUTUBXONASI - ТУРКЕСТАНСКАЯ БИБЛИОТЕКА

Өченчесе: "Миңа икесе дә бер", – ди.
(*Чана, арба, ат*)

* Ишекле-түрле йөри, эләккәнне сөйри.
(*Себерке*)

* Бәләкәй генә углан
Биленә каеш буган.
(*Себерке*)

* Бәләкәй генә бичура
Билен буып утыра.
(*Себерке*)

* Йөз дә бер агай бергә торалар.
(*Себерке*)

* Мең туган бер каеш буган.
(*Себерке*)

* Яшел күлмәк кигән,
Билен буган,
Ишекле-түрле йөгерә.
(*Себерке*)

* Җәй булса, ябылмый; кыш булса, ачылмый.
(*Тәрәзә*)

* Ике туган караша,
Киләалмый янәшә.
(*Тәрәзәләр*)

* Өй түрендә дүрт табак,
Дүртесе дә күк табак.
(*Тәрәзәләр*)

* Өй тирәли ак тавык.
(*Тәрәзә пәрдәсе*)

* Дүрт кешегә бер эшләпә.
(*Өстәл*)

* Бер кешедә дүрт аяк,
Дүртесе дә пар аяк.
(*Өстәл*)

* Бер башлы, дүрт аяклы,
Алай да күтәрмичә йөрми.
(*Өстәл*)

TURKISTAN KUTUBXONASI - ТУРКЕСТАНСКАЯ БИБЛИОТЕКА

* Аягы бар, кулы юк,
Аркасы бар, түше юк.
(*Урындык*)

* Үзе түгәрәк, утыны түрдәрәк, эче тулы күзәнәк;
Әчкелтем дә төчкелтем, бар нәрсәдән дә кадерлерәк.
(*Икмәк*)

* Сыек булса да су түгел,
Ак булса да карт түгел,
Йомшак булса да йон түгел.
(*Сөт*)

* Су түгел – сыек,
Кар түгел – ак.
(*Сөт*)

* Кисмәк таптым кыршаусыз,
Ул да булды капкачсыз.
(*Йомырка*)

* Бер кисмәктә ике төрле бал.
(*Йомырка*)

* Бер чүлмәктә ике төрле май.
(*Йомырка*)

* Бәләкәй генә ак келәт,
Эче тулы сары май.
(*Йомырка*)

* Эче сары, тышы ак,
Ул ни булыр? – Әйтеп бак!
(*Йомырка*)

* Ак толып җөйсез генә тегелгән.
(*Йомырка*)

* Үзе кием, үзе тун,
Үзе тегелмәгән.
(*Сарык тиресе*)

* Үзе җансыз,
Көн бара, төн бара,
Бер карыш җир бара.
(*Сәгать*)

* Гел йөрим дип мактана,
Бер урында таптана.
(*Сәгать*)

TURKISTAN KUTUBXONASI - ТУРКЕСТАНСКАЯ БИБЛИОТЕКА

* Башы бер, күзе унике.
(*Сәгать*)

* Атламый – йөри.
(*Сәгать*)

* Аяксыз йөри,
Кулсыз күрсәтә.
(*Сәгать*)

* Аягы юк – йөри,
Авызы юк – сөйли,
Иртәсен дә, кичен дә
Һаман да үз эшендә.
(*Сәгать*)

* Көн-төн йөри,
Урыныннан китә алмый.
(*Сәгать*)

* Ай түгел, көн түгел,
Үзе вакытны белдерә.
(*Сәгать*)

* Ап-ак йөзле,
Унике күзле,
Ике телле,
Өйрәтә һәркемне.
(*Сәгать*)

* Ашамый-эчми.
Көне-төне эшли.
(*Сәгать*)

* Җансыз җанлыны уята.
(*Будильник сәгать*)

* Ач булса – ята, тук булса – торып утыра.
(*Капчык*)

* Кечкенә генә кыз бала
Йөрәгенә ут сала.
(*Самавыр*)

* Башы да тишек,
Төбе дә тишек,
Уртасында ут,
Читендә су.
(*Самавыр*)

TURKISTAN KUTUBXONASI - ТУРКЕСТАНСКАЯ БИБЛИОТЕКА

* Эчендә су да бар, ут та бар,
Ул үзе һәр йортта бар.
(*Самавыр*)

* Карынында – ут,
Корсагында – су,
Башында – төпсез эшләпә,
Менә дөнья нишләтә.
(*Самавыр*)

* Бәләкәй генә ак тана
Борыным бар дип мактана.
(*Чәйнек*)

* Эче куыш, тышы таш,
Түбәтәе орчыкбаш.
(*Чәйнек*)

* Эче кайнар,
Борыныннан агар,
Бер кулы бар, –
Ул да аркасында.
(*Чәйнек*)

* Шар чаклы күзе бар,
Йодрык чаклы үзе бар.
(*Чынаяк*)

* Табышмагымның табы кара,
Тапмаганның йөзе кара.
(*Таба*)

* Бәләкәй генә тай,
Төбе чеп-чи май.
(*Таба*)

* Авызы юк, тешле.
(*Пычкы*)

* Аягы юк, кулы бар,
Авызы юк, теше бар,
Таш тегермән булмаса да,
Ярма ярыр эше бар.
(*Пычкы*)

* Җырлый-җырлый әйбер кисә,
Әйтеп бирче, бу нәрсә?
(*Пычкы*)

TURKISTAN KUTUBXONASI - ТУРКЕСТАНСКАЯ БИБЛИОТЕКА

* Тиз ашый, вак чәйни,
Үзе йотмый, башкага бирми.
(*Пычкы*)

* Эләктергеч, каптыргыч,
Мичтән бәлеш тарттыргыч.
(*Табагач*)

* Табышмак әйтәм тап:
Коймаклы табаны кап.
(*Табагач*)

* Өй эчендә түгәрәк күл.
(*Тәлинкә*)

* Үзе бер дә ашамый,
Ашаганда бушамый.
(*Кашык*)

* Ашаганда бик кирәк,
Ашамаганда ник кирәк?
(*Кашык*)

* Үрдәк чума китәр,
Койрыгы чыга китәр.
(*Чүмеч*)

* Башы суда, койрыгы чөйдә.
(*Чүмеч*)

* Бер саплы да бер төпле,
Үзе куыш.
(*Чүмеч*)

* Аркасы бар, эче юк,
Муены бар, башы юк.
(*Чүмеч*)

* Үзе йомры, үзендә су тора.
(*Чиләк*)

* Ике агай-эне су коенырга баралар.
(*Ике чиләк белән суга бару*)

* Ике туган суга бара,
Берсен-берсе уза бара.
(*Чиләкләр*)

TURKISTAN KUTUBXONASI - ТУРКЕСТАНСКАЯ БИБЛИОТЕКА

* Ике агай су коена:
Берсе чума, берсе күтеп тора.
(*Чиләкләр*)

* Кырык төштән билен буган,
Утыз чиләк аш ашый.
(*Кисмәк*)

* Борыны борсак,
Карыны корсак,
Җәяү дә йөрмәс,
Тик тә тормас.
(*Комган*)

* Гармун кебек сырлы ул,
Мич шикелле җылы ул.
(*Җылыткыч батарея*)

* Багана яна, күмере-көле юк.
(*Шәм*)

* Караңгы өйдә ак кына бер кыз,
Авызы тулы балавыз, –
Борынын сөртсәң, ялт итә.
(*Шәм*)

* Сыңар күзле ябалак
Төне буе ялтырый.
(*Шәм*)

* Өстәлемдә бер гөмбә,
Яктыртып тора төнлә.
(*Өстәл лампасы*)

* Үзе яна – яндырмый.
(*Электр лампасы*)

* Төймәсе челт итә,
Үзе гөлт итә.
(*Электр лампасы*)

* Гәүдәсе өйдә,
Муены тышта.
(*Мич һәм морҗа*)

* Үзе ак күлмәк кигән,
Башы түшәмгә тигән,
Аягы җиргә тигән.
(*Мич*)

TURKISTAN KUTUBXONASI - ТУРКЕСТАНСКАЯ БИБЛИОТЕКА

* Үзе өйдә, чәче урамда.
(*Мич, төтен*)

* Өй эчендә базым бар,
Баз эчендә бозым бар,
Керер идем, сыялмыйм,
Бозларында шуалмыйм.
(*Суыткыч*)

* Кечкенә генә өй,
Эче тулы көй.
(*Магнитофон*)

* Үзе сөйли, үзе җырлый,
Ә үзенең теле юк.
(*Радиоалгыч*)

* Бер күзгегә дөнья сыйган.
(*Телевизор*)

* Бер пыяла эчендә мең кеше.
(*Телевизор*)

* Ак ашъяулык яптык,
Эченә бактык.
Бер минутта кышын да таптык,
Язын да таптык.
(*Телевизор экраны*)

* Тирән күлдә балык юк.
(*Кое*)

* Сыңар аяк бер торна
Коега сузылып су эчә.
(*Коедан су алу*)

* Ике туган суга бара,
Берсен-берсе уза бара.
(*Ике чиләк белән суга бару*)

* Өйдән чыкканда җип-җиңел булалар,
Өйгә кергәндә, мөлдерәп тулалар;
Парлашып-җырлашып баралар,
Елашып, ыңгырашып кайталар.
(*Сусыз һәм сулы чиләкләр*)

* Сыңар аяк саескан
Суга төшеп су эчкән.
(*Чүмеч*)

TURKISTAN KUTUBXONASI - ТУРКЕСТАНСКАЯ БИБЛИОТЕКА

* Аттан биек, эттән тәбәнәк.
(Ияр)

* Алты аяклы, ике куллы,
Ике башлы, бер койрыклы.
(*Җайдак (атка атланган кеше)*)

* Бер авызлы, мең күзле.
(*Иләк*)

* Үзе яңа, үзе тишек.
(*Иләк*)

* Урманга барып бөктем,
Өйгә кайтып тектем,
Уртасында иһа-һай.
(*Иләк*)

* Урманда бөгелгән,
Өйдә тегелгән,
Өр-яңа савыт, –
Төбе тишелгән.
(*Иләк*)

* Болытсыз көнне яңгыр ява.
(*Он иләү*)

* Озын идем – киселдем,
Юан идем – ярылдым,
Инде утка тарыдым.
(*Утын*)

* Дәшми ятар, дәшми тотар.
(*Капкын*)

* Чәчен-башын туздырган,
Атасыннан уздырган.
(*Пумала*)

* Мич артында картыгыз,
Сакалыннан тартыгыз.
(*Пумала*)

* Урманнан килгән,
Яшел күлмәген кигән;
Уңга-сулга селтәли,
Кешеләрне шелтәли.
(*Мунча себеркесе*)

* Армый-талмый, ат артыннан калмый.
(*Арба*)

* Бар бер чана,
Утырасы юк, бассаң – үзе чаба.
(*Чаңгы*)

* Җәй буе ял итәрләр,
Кыш тәпиләп китәрләр.
(*Чаңгы*)

* Күзе дә юк, колагы да юк;
Үзе сукырны җитәкли.
(*Таяк*)

* Атласам – атлый,
Туктасам – туктый,
Барып керсәм өйгә,
Сөялә дә тик тора.
(*Таяк*)

* Бер түгәрәктә дүрт тишек.
(*Төймә*)

* Үзе бара, эзе юк, маңгаенда күзе юк.
(*Көймә*)

* Миннән ничаклы алсалар.
Шулкадәр зурая барам.
(*Чокыр казу*)

* Үзе бер дә ашамый, ашаганда бушамый.
(*Кашык*)

* Ике оч, ике балдак,
Уртасында бер кадак.
(*Кайчы*)

* Ике кулча, уртасында бер төймә.
(*Кайчы*)

* Җиңги куш бармагын ачса,
Абзый авызын ача,
Җиңги йомса – йома.
(*Кайчы*)

* Агасы турый, энесе ялгый.
(*Кайчы һәм энә*)

TURKISTAN KUTUBXONASI - ТУРКЕСТАНСКАЯ БИБЛИОТЕКА

* Килеп керде бер кеше, маңгаенда бер күзе.
(*Энә*)

* Бөтен дөньяны киендерә, үзе ялангач.
(*Энә, җеп*)

* Үзе бер карыш,
Сакалы биш карыш.
(*Энә, җеп*)

* Тимер тычкан, сүс койрык.
(*Энә, җеп*)

* Койрыгы – башында,
Колагы – күзендә.
(*Энә, җеп*)

* Тек-тек итәр,
Текмештән китәр.
(*Тегү машинасы*)

* Ай киттем, ел киттем,
Инә буе җир киттем.
(*Тегү*)

* Ялгыз гына ашалмый,
Аннан башка аш бармый.
(*Тоз*)

* Читтән карасам – аклы,
Татып карасам – татлы.
(*Шикәр*)

* Икесе дә ак, икесе дә вак,
Аерыйм дисәң – кап.
(*Тоз һәм шикәр комы*)

* Бәләкәй генә оя, җитмеш биш кеше сыя.
(*Шырпы кабы*)

* Бер өйдә җитмеш кеше, -
Барысы да чалмалы.
(*Каплы шырпы*)

* Каравыл өендә алтмыш янгынчы.
(*Каплы шырпы*)

* Күрергә күркәм,
Тотарга куркам.
(*Ут*)

TURKISTAN KUTUBXONASI - ТУРКЕСТАНСКАЯ БИБЛИОТЕКА

* Нәрсә ашый авызсыз?
(*Ут*)

* Ашатсаң – яши,
Эчертсәң – үлә.
(*Ут*)

* Ялт-йолт итәр,
Ялмап китәр.
(*Ут*)

*Аягы юк, кулы юк,
Тиз йөгерә, тиз җиңә.
(*Ут*)

* Өй түбәсендә кызыл әтәч кычкыра.
(*Янгын*)

* Мич эчендә кара мәче.
(*Төтен*)

* Йөгереп чыга, җилгә оча.
(*Төтен*)

* Аягы юк – качадыр,
Канаты юк – очадыр.
(*Төтен*)

* Өй башында аю тузан туздыра.
(*Төтен*)

* Син аны тота барасың, ул синнән кача бара.
(*Акча*)

* Күзе юк, тезе юк,
Йөрмәгән жире юк,
Кермәгән кулы юк.
(*Акча*)

* Сырлы-сырлы, сырлы ул,

* Безнең белән җырлый ул.
(*Гармун*)

* Телләре бар – сөйләми,
Көйләре бар – теләмәсә, көйләми.
(*Гармун*)

* Тәне җыерчыклы, күзе юк,
Үзе телле, ләкин сүзе юк;

TURKISTAN KUTUBXONASI - ТУРКЕСТАНСКАЯ БИБЛИОТЕКА

Бармагы күп тә, аз да,
Кызыга аңа яшь тә, карт та,
Егет тә, кыз да.
(*Гармун*)

* Сары сандык сатып алдым, –
Үзе нәни генә,
Төрле тавышка җырлый белә.
(*Скрипка*)

* Авызы бар – теле юк,
Тавышы бар – сүзе юк.
(*Курай*)

* Авызы юк – кычкыра,
Теле юк – чакыра.
(*Быргы*)

* Җебенә тисәң – елаган,
Колагын тотсаң – чыңлаган;
Өстендә бар эчәге,
Астында бар түшәге.
(*Думбра*)

* Бер чокырда мең чокыр.
(*Уймак*)

* Үзе бер, күзе мең.
(*Уймак*)

* Алтын башлы, көмеш күзле.
(*Уймак*)

* Гәүдәсеннән койрыгы озын.
(*Камчы*)

* Бара-бара, эзе юк; кисә-кисә, каны юк.
(*Көймэ. ишкәк ишү*)

* Авызы юк, теше бар,
Ашаганын йоталмый,
Кулы белән тоталмый.
(*Пычкы*)

* Авызы – йон, борыны – бармакча.
(*Йон бияләй*)

* Һичкайчан да ул кешедән калмыйдыр,
Һәм кеше дә аннан үзе калмыйдыр.
(*Кием*)

TURKISTAN KUTUBXONASI - ТУРКЕСТАНСКАЯ БИБЛИОТЕКА

* Җиңе бар – күлмәк түгел,
Бавы бар – алъяпкыч түгел.
(*Халат*)

* Биле бормалы,
Чите укалы,
Үзе бәһале.
(*Камзул*)

* Баш-аяксыз – буе бар,
Гәүдәсе юк – кулы бар.
(*Күлмәк*)

* Бер ягы кыр, бер ягы урман.
(*Тун*)

* Тәкә тунын салдырдым,
Шуны үзем ябындым.
(*Тун*)

* Аеры ике, төбе бер.
(*Чалбар*)

* Ике тавык бер төптә,
Аерылмыйлар бөртек тә.
(*Чалбар*)

* Бер кеше ике юлдан бара.
(*Чалбар*)

* Алды да койрык,
Арты да койрык.
(*Шарф*)

* Кара тавык кар ера.
(*Киез итек*)

* Җәй көне чоланда ята,
Кыш көне бездән калмый.
(*Киез итек*)

* Башы бар – мие юк,
Биле бар – бавы юк,
Гәүдәсе бар – эче юк.
(*Итек*)

* Башы бар, авызы юк,
Җылысы бар, миче юк.
(*Итек*)

TURKISTAN KUTUBXONASI - ТУРКЕСТАНСКАЯ БИБЛИОТЕКА

* Ике агай тездән,
Калышмыйлар бездән.
(*Пар итек*)

* Биш агайга бер күлмәк.
(*Йон бияләй*)

* Эче мамык, тышы кабык.
(*Тире бияләй*)

* Бер агачта биш тармак,
Тармагы саен бармак.
(*Пирчәткә*)

* Җәеп тотсаң - табактай,
Җыеп тотсаң – таяктай.
(*Кулчатыр (Зонтик)*)

* Өстән су ага,
Астан кеше бара.
(*Зонтик*)

* Тамчылары ялтырый,
Тамалмыйча калтырый.
(*Алка*)

* Аяксыз-кулсыз күлмәк кияр.
(*Мендәр*)

* Кызу табанлы чана, –
Ат җигелмәгән аңа, –
Бер чигенә, бер бара,
Юлы шомарып кала.
(*Үтүк*)

* Кораб йөзә килә,
Күлне көйдерә килә.
(*Үтүк*)

* Тимер тәкә боз шуа.
(*Үтүк*)

* Колагы бар, башы юк,
Ашамаган ашы юк.
(*Миски*)

* Үземне пешерәләр – ашамыйлар.
(*Сөяк*)

* Кайчысыз киселә, җепсез тегелә.
(*Пилмән ясау*)

* Әйләнгән саен калыная.
(*Йомгак*)

* Койрыгыннан тартсаң, эчәге чыгып бетә.
(*Йомгак*)

* Бәләкәй генә әби
Йөгерә-йөгерә йон җыяр.
(*Орчык*)

* Йөгерә-йөгерә йөк җыяр.
(*Орчык*)

* Үзе йөри – атламый.
Өерелүдән туктамый.
(*Орчык*)

* Бер әйләнсә һаман әйләнә,
Әйләнгән саен байый һәм калыная.
(*Орчык*)

* Дүрт татар читән үрә,
Берсе арада йөри.
(*Оек-бияләй бәйләү*)

* Ун оста, биш бармак
Арканнан бура бурыйлар.
(*Оек-бияләй бәйләү*)

* Биш агай бер-берсен тота алмыйлар.
(*Оек-бияләй бәйләү*)

* Кечкенә генә үзе,
Маңгаенда күзе,
Күрсә, онытмый үзе.
(*Фотоаппарат*)

* Кешесе бар, җаны юк.
(*Фоторәсем*)

* Үзе миңа карап тора,
Үзе мине күрми.
(*Фоторәсем*)

* Үзе сукыр, кешегә юл күрсәтергә оста.
(*Компас*)

TURKISTAN KUTUBXONASI - ТУРКЕСТАНСКАЯ БИБЛИОТЕКА

* Сөйләп бирә тел белән,
Сүзе китә юл белән, -
Юлы агач башында.
(*Телефон*)

* Үзе монда утыра,
Сүзне тегендә тутыра.
(*Телефон*)

* Колагы юк – ишетә,
Авызы юк – сөйли.
(*Телефон һәм радио*)

* Акылы бар, җаны юк.
(*Үлчәү*)

* Күрергә күзе юк,
Сөйләргә теле юк,
Үзе саный.
(*Үлчәү*)

* Үзе күрми, кешегә күрсәтә,
Үзе өйрәнми, кешегә өйрәтә.
(*Үлчәү*)

* Ике аяклы үгез,
Маңгаенда куш мөгез.
(*Велосипед*)

* Арбасы бар, аты юк,
Тәртә-мазар заты юк;
Тоткасына кулың тисә,
Атны да узып китә.
(*Автомобиль*)

* Тавышлана – җил түгел,
Канаты бар – кош түгел;
Һавада оча,
Болытлар коча.
(*Самолет*)

* Канаты бар, йоны юк;
Үзе бара, юлы юк.
(*Самолет*)

* Аккош оча,
Эзе кала,
Үзе китеп югала.
(*Самолет*)

TURKISTAN KUTUBXONASI - ТУРКЕСТАНСКАЯ БИБЛИОТЕКА

* Кош та түгел, ат та түгел,
Үзе оча, йөк ташый.
(*Самолет*)

* Кешеләрне очырта,
Үзе кошка охшамый;
Зонтик кебек җәелсә дә,
Җил-яңгырдан сакламый.
(*Парашют*)

* Баш очымда чатырым,
Очтым алты чакырым,
Очып төшкәч кайтырым.
(*Парашют*)

* Тигез җирдән киталмый,
Үргә таба меналмый,
Түбән таба тукталмый.
(*Туп*)

* Йөгерә белми, сикерә белә.
(*Туп*)

* Җәй буе сикерә,
Кыш буе тик тора.
(*Уенчык туп*)

* Үзе кеп-кечкенә,
Үзе миннән биек сикерә.
(*Уенчык туп*)

* Миннән бик күп тәбәнәк,
Үзе йөри тәгәрәп.
(*Туп*)

* Күтәреп җиргә бәрдем,
Күктән, тотып алдым.
(*Туп*)

* Минем белән уйныйлар,
Кулларыннан куймыйлар,
Иркәлиләр, сөяләр,
Йокла, иркәм, дияләр.
Үсә төшкәч, балалар
Мине онытып калалар.
(*Курчак*)

* Барасың, барасың,
Башына чыгалмыйсың.
(*Юл*)

TURKISTAN KUTUBXONASI - ТУРКЕСТАНСКАЯ БИБЛИОТЕКА

* Алда да бар, артта да бар,
Борылган да сырылган,
Озын булып сузылган.
(*Юл*)

* Тап табышмак: табага ябышмак.
(*Коймак пешерү*)

* Аягы йөрми, таягы йөри.
(*Чалгы, печән чабу*)

* Инәсеннән элек баласы туар.
(*Чүмәлә белән кибән*)

**VIII бүлек.**
**Кеше, аның әгъзалары**

* Зур мичкә.
Зур мичкә өстендә кечкенә мичкә,
Кечкенә мичкә өстендә кара урман.
(*Кеше гәүдәсе*)

* Бер бүкәндә җиде тишек.
(*Баш*)

* Кары күренмәгән кара урман.
(*Чәч*)

* Ике агай суга бара,
Берсен берсе уза бара.
(*Аяклар*)

* Өй түбәсендә чаңгы юлы.
(*Чәч юлы*)

* Кечкенә генә сарай,
Эчендә бии утыз ике малай.
(*Авыз һәм тешләр*)

* "Ач!" – дисәң, ачыла,
"Яп!" – дисәң, ябыла.
(*Авыз, иреннәр*)

* Кечкенә генә җилкапка,
Ачыла да ябыла.
(*Авыз, иреннәр*)

* "Ти", – дисәң, тими,
"Тимә", – дисәң, тия.
(*Авыз, иреннәр*)

* Кечкенә генә мич астында кызыл ут яна.
(*Авыз һәм тел*)

* Оясыннан чыгып өрә дә кереп кача.
(*Авыз, тел*)

* Үзе сөяксез,
Сөйләгән сүзе хисапсыз.
(*Тел*)

* Сөйдергән дә шул,
Биздергән дә шул,
Иң татлы да шул.
Иң ачы да шул.
(*Гел*)

* Ике туган игез,
Икесе дә тигез.
(*Ике кул*)

* Ике учымда ун бала.
(*Ике кулдагы бармаклар*)

* Ике ананың ун баласы,
Бар да бер исемле.
(*Ике кул, бармаклар*)

* Бер ананың биш баласы,
Кайсын тешләсәң, шунсы авырта.
(*Кул һәм бармаклар*)

* Багана башында биш такыя.
(*Кул, бармаклар*)

* Биш туган бергә яши,
Берсеннән-берсе кечерәк.
(*Бармаклар*)

* Без – ун агай,
Уныбызга бер исем.
(*Ике кулдагы бармаклар*)

* Өй эчендә биш бала,
Билгесендә биш тана.
(*Кул, бармаклар, тырнаклар*)

TURKISTAN KUTUBXONASI - ТУРКЕСТАНСКАЯ БИБЛИОТЕКА

* Таралгач – биш,
Җыелгач – бер.
(*Бармаклар, йодрык*)

* Үлгәнче үзең белән,
Күрмисең күзең белән.
(*Иңсә*)

* Җәрәхәте юк – авырта,
Төтене юк – яна.
(*Йөрәк*)

* Икәү карап тора,
Икәү тыңлап тора,
Берәү сайрап тора.
(*Күзләр, колаклар, тел*)

* Сөяге юк, ние юк, сөйләмәгән сүзе юк.
(*Тел*)

* Кечкенә генә җилкапка ачыла да ябыла.
(*Авыз*)

* Тия-тия дисәң, тимидер,
Тими-тими дисәң, тиядер.
(*Ireннәр*)

* Бер анада биш бала.
(*Кул*)

* Бер агачта ике яфрак.
(*Гәүдә һәм колаклар*)

* Яр буенда ярты алачык.
(*Колак*)

* Бер тау тирәли ике тишек чүмеч эленгән.
(*Колак*)

* Тау битендә бер амбар,
Аның ике ишеге бар, -
Бервакытта ябылмый,
Көне-төне җил уйный.
(*Борын*)

* Йоклаганда бүрәнә тарталар.
(*Борын тишекләре*)

* Ансыз дөнья сансыз.
(*Тешләр*)

TURKISTAN KUTUBXONASI - ТУРКЕСТАНСКАЯ БИБЛИОТЕКА

* Кечкенә генә келәттә утыз ике капчык.
(*Авыз һәм тешләр*)

* Кечкенә генә абзарымның
Эче тулы ак тавык.
(*Авыз, тешләр*)

* Кечкенә генә сарай,
Эчендә бии утыз ике малай.
(*Авыз, тешләр*)

* Түгәрәк күлдә алтын таш,
Ау салсаң да алынмас.
(*Авыз, тешләр*)

* Сөяк келәт, ит бастырык.
(*Тешләр һәм тел*)

* Утыз ике ак ат,
Бер чыгымчы җирән ат.
(*Тешләр, тел*)

* Көмеш сарай эчендә
Чаптар айгырым кешнидер.
(*Тешләр, тел*)

* Сөяк абзар, кабык ишек.
(*Тешләр, иреннәр*)

* Койма коелган,
Каплап куелган,
Әмма җил тормый.
(*Тешләр, иреннәр, сөйләшү*)

* Тирән күл – суы акмый.
(*Күз*)

* Кечкенә генә чүлмәктә
Елтыр-елтыр май кайный.
(*Күз*)

* Абыйсы белән сенлесе
Күпер аркылы яшиләр,
Берсен берсе күрмиләр.
(*Күзләр*)

* Ике агай рәттән торсалар да,
Бер-берсен күрмиләр.
(*Күзләр*)

TURKISTAN KUTUBXONASI - ТУРКЕСТАНСКАЯ БИБЛИОТЕКА

* Тәртәсе бар, аты юк,
Күзләре бар, башы юк.
(*Күзлек*)

* Бик күп укый, бер дә белеме юк.
(*Күзлек*)

* Ике батыр.
Аяк юлы ятыр.
(*Каш*)

* Елтыр-елтыр ике таш,
Уртасында кара таш.
(*Ике күз*)

* Йөзлек астында йөз энә.
(*Керфекләр*)

* Ялт-йолт ябыла, –
Йозаксыз бикләнә.
(*Керфекләр*)

* Түгәрәк күлем ташый.
(*Күз яше*)

* Тау битендә бер амбар,
Аның ике ишеге бар, –
Бервакытта да ябылмый,
Көне-төне җил улый.
(*Борын*)

* Алтын сандык эчендә
Ачылмаган хатым бар.
(*Ми, хәтер*)

**IX бүлек.**
**Тапкырлар, зирәкләр өчен табышмаклар**

* Һәркемдә бар. Ул нәрсә?
(*Исем*)

* Чәйдә ни тормас?
(*Кукәй*)

* Төшсә суга батмыйдыр,
Ут кабынса янмыйдыр,
Кумсәң җиргә чермидер,
Беләсезме, ул нидер?
(*Кешенең исеме*)

TURKISTAN KUTUBXONASI - ТУРКЕСТАНСКАЯ БИБЛИОТЕКА

* Казанның уртасында ни бар?
(*"З" хәрефе*)

* Дөньяда иң кирәк,
Иң кирәктән ни кирәк?
(*Саулык, аны саклау*)

* Бер тавык – тавык, ике тавык нәрсә?
(*Тавыклар*)

* Ашъяулык янына килеп утыруга нәрсә кирәк була?
(*Авыз*)

* Нинди савыттан эчеп булмый?
(*Буш савыттан*)

* Патша кемгә баш ия?
(*Чәчтарашка*)

* Су кайда коры була?
(*Картада*)

* Өй эчендә ни күренми?
(*Җылылык*)

* Иртән дүрт аяк,
Төштә ике аяк,
Кич өч аяк,
Өстендә була маяк.
(*Кеше гомере*)

* Суда нинди таш булмый?
(*Коры таш*)

* Нинди тарак тарарга ярамый,
Нинди урак урырга ярамый?
(*Әтәчнең кикриге һәм койрыгы*)

* Ат чаба-чаба да, нәрсәдән ары китә алмый?
(*Койрыгыннан*)

* Бер секунд эчендә бөтен җир шарын әйләнеп чыга.
(*Уй-фикер*)

* Кем барлык телләрдә дә сөйли ала?
(*Кайтаваз*)

* Кайсы елда кешеләр күбрәк ашый?
(*Кәбисә елда. Чөнки бер көне артык*)

TURKISTAN KUTUBXONASI - ТУРКЕСТАНСКАЯ БИБЛИОТЕКА

* Чакырсаң да килми,
Кусаң да китми.
(*Байлык һәм фәкыйрьлек*)

* Нәрсәне сатып алып булмый?
(*Үткән гомерне*)

* Каз нигә йөзә?
(*Аягы су төбенә тимәгәнгә*)

* Иң җиңелне капка аркылы ыргытып булмый?
(*Йонны*)

* Бушка килә, акчага китә.
(*Чир*)

* Яңгыр яуганда куян нинди куак астында утыра?
(*Юеш куак астында*)

* Кеше үзенең нәрсәсен күтәрә алмый?
(*Күләгәсен*)

* Сыер нигә ята?
(*Утыра алмаганга*)

* Берсе – бер айлык,

* Берсе – саклап тотсаң гомерлек.
(*Байлык һәм фәкыйрьлек*)

* Үлчәүләрдә үлчәнми,
Базарларда сатылмый.
Үзеңнеке булмаса,
Кешедән сатып алынмый.
(*Бәхет*)

* Бер имәндә өч ботак, ботак саен өчәр алма, ничә алма була?
(*Имәндә алма булмый*)

* Каз судан чыккач нишли?
(*Коры җиргә баса*)

* Карга җидене тутыргач нишли?
(*Сигезгә чыга*)

* Ул минем этиемнең улы,
Үзе миңа туган түгел.
(*Кеше үзе*)

TURKISTAN KUTUBXONASI - ТУРКЕСТАНСКАЯ БИБЛИОТЕКА

* Ат нигә улак янына бара?
(*Улак үзе килмәгәнгә*)

* Дөньяда иң житез нәрсә?
(*Уй*)

* Кем туганда ук сакаллы булып туа?
(*Кәҗә*)

* Кәҗә судан ничек чыга?
(*Юешләнеп*)

* Урман белән тау арасында нәрсә бар?
(*"Белән" сүзе*)

* Алманың яртысы нәрсәгә охшаган?
(*Икенче яртысына*)

* Ачыдан ачы – ни ачы?
Татлыдан татлы – ни татлы?
Катыдан каты – ни каты?
(*Үлем, йокы, ат тоягы*)

* Беренче кисәге – Җирнең иярчене,
Икенче кисәге – җәзалау урыны,
Кушып укыганда – кеше исеме.
(*Айдар*)

* Кешегә иң якын әйбер нәрсә?
(*Күлмәк*)

* Бүрегенә чыпчык кунганда каравылчы нишли?
(*Йоклый*)

* "К" дән башлап укысагыз,
Җир ашларга китә;
"Г"дән башлап укысагыз,
Чәчәк атып үсә.
(*"Көл" һәм "гөл"*)

* Үзе шар, үзен беркем дә тәгәрәтә алмый.
Нәрсә ул?
(*Җир шары*)

* Нәрсәне күрү иң җиңел?
(*Кеше гаебен*)

* Эреми дә, череми дә.
(*Усаллык*)

* Тоз түгел – ачы,
Кылыч түгел – үткер,
Ут түгел – яндыра.
(*Кайгы*)

* "Табышмак" сүзен ничек укырга кирәк?
(*Сулдан уңга таба*)

* Дөньяда нәрсә тамырсыз үсә?
(*Таш*)

* Сыерда бар, атта юк,
Сарыкта бар, эттә юк.
(*"С" хәрефе*)

* Беренче кисәге - боерык фигыль,
Икенче кисәге – иген үсә торган җир,
Кушып укыганда – зирәк кеше.
(*"Тапкыр" сүзе*)

* Тугай кайчан сайрый?
("*Р" хәрефен өстәгәч*)

* Кемнең сакалын кырдырырлык та акчасы юк?
(*Кәҗәнең*)

* Сигез таякның дүртесен сындыргач, нәрсә кала?
(*Унике таяк кала*)

* Кайсы ай календарьда юк?
(*Һавадагы ай*)

* Сөрмәгән җир өстендә,
Үсмәгән каен астында
Тумаган куян йөгерә.
(*Хыял*)

* Ике әти, ике бала, – үзләре өчәү генә.
(*Бабай, ата, ул*)

* Бернәрсә дә ашамыйча ничә йомырка ашап була?
(*Берне*)

* Нәрсәне йомык күз белән дә күреп була?
(*Төшне*)

* Нинди сан исем дә була ала?
(*Йөз*)

TURKISTAN KUTUBXONASI - ТУРКЕСТАНСКАЯ БИБЛИОТЕКА

* Биш йөз баш, мең аяк, бер койрык. Ул нәрсә?
(*Чират*)

* Кем үзенең туган көнен дүрт елга бер генә мәртәбә уздыра?
(*29 февральдә туган кеше*)

* Юләр кайчан акыллы була?
(*Тик торганда*)

* Кеше, кеше белән саубуллашкач, нигә артына әйләнеп карый?
(*Артында күзе булмаганга*)

* Нәрсәне сатып алып булмый?
(*Үткән гомерне*)

* Бер килограмм тимер авырмы, бер килограмм мамыкмы?

(*Икесе дә бер*)

* Нинди сәгать тәүлеккә ике генә мәртәбә вакытны дөрес күрсәтә?
(*Туктаган сәгать*)

* Дөнья йөзендә җиде нәрсәдә җиде юк. Нәрсәләр?
(*Күгәрченнең сөте, атның мөгезе, йомырканың җөе, сыерның ялы, ташның тамыры, еланның аягы, мәченең сакалы*)

* Машинаның кайсы тәгәрмәче әйләнми?
(*Запас тәгәрмәче*)

* Бал-шикәрдән татлы,
Үзен ашап булмый.
(*Йокы*)

* Ике көн рәттән яңгыр явамы?
(*Рәттән ике көн булмый, арада төн бар*)

* Көн белән төн бер-берсеннән нәрсә белән аерылалар?
(*Беренче хәрефләре белән*)

* Суны кайчан иләк белән ташып була?
(*Карга әйләнгәч*)

* Кайда тавык тилгәннән курыкмый?
(*Кетәгендә*)

* Җир өстендә кешеләр нинди авыру белән бер дә авырмыйлар?
(*Диңгез авыруы белән*)

TURKISTAN KUTUBXONASI - ТУРКЕСТАНСКАЯ БИБЛИОТЕКА

* Нинди ут яндырмый?
(*Рәсемдәге ут*)

* Аучы мылтык атканда ни өчен бер күзен йома?
(*Икесендә йомса, бернәрсә дә күрә алмый*)

* Агач башында сигез кош утыра иде. Аучы аларның икесен атып алды. Ничәү калды?
(*Берсе дә калмады*)

* Бер өйдә торалар ике ана, ике кыз, әби оныгы белән. Барысы ничә кеше була?
(*Әби, ана, кыз*) ,

* Бер ата белән бер ананың баласы, ләкин үзе аларның улы түгел.
(*Кыз бала*)

* Булган, ди, бер карт белән карчык; аларның бер кызы, бер малайлары булган; шул малайларның карт белән карчыклары, ә шул карт белән карчыкның бер кыз, бер малайлары булган. Бу ничек?
(*Ата, ана, кыз, ул*)

* Утыз "я" хәрефеннән торган кеше исеме.
(*Зоя*)

* Башы – "т", койрыгы – "н",
Дошманы – "м". Ул нәрсә?
(*Тычкан*)

* Нәрсәсез өй салып булмый?
(*Почмаксыз*)

* Базарда табылмас,
Үлчәүдә үлчәнмәс,
Аннан татлы нәрсә булмас.
(*Йокы*)

* Нинди агач утта янмый?
(*Табагач*)

* Бөтен татар өендә бар,
Үзе дөньяда бер генә.
(*Казан*)

* Нәрсәне урыныннан кучереп булмый?
(*Җирне*)

TURKISTAN KUTUBXONASI - ТУРКЕСТАНСКАЯ БИБЛИОТЕКА

* Күтәреп була, ыргытып булмый. Ул нәрсә?
(*Мамык*)

* Нинди савыттан эчеп булмый?
(*Буш савыттан*)

* Кешегә иң якын әйбер нәрсә?
(*Күлмәк*)

* Кунган кошны куркытмыйча гына ничек итеп агач ботагын кисеп алырга?
(*Кош үзе очып киткәч*)

* Ике ата, ике угыл бакчада йөргәндә дүрт алма өзеп, һәрберсе берәрдән ашасалар да, кулларында янә бер алма артып калган. Ул ничек була?
(*Бабай, ата, ул*)

* Куянның арт аягы нигә озын?
(*Ал аягы кыска булганга*)

* Нинди дәрьяның суы кимеми?
(*Күзнең*)

* Бер тартмада алмалар бар.
Алмаларны алгач анда нәрсә кала?
(*Һава*)

* Әй, егет, бу ничек була? Минем өч икмәгем бар.
Берсе белән алган бурычымны түлим, икенчесен әҗәткә бирәм, өченчесен үзем ашыйм.
(*Ата-анасына, баласына, үзенә*)

* Кем ике мәртәбә дөньяга туа?
(*Чебеш*)

* Түтәлдә нинди ике нота үсә?
(*Фасоль*)

* Борынга керә, күтәреп булмый.
(*Ис*)

* Кыш көнендә күп була торган ике нәрсәнең исеменнән килеп чыккан бакча җимеше.
(*Карбыз*)

* Кара дисәң, карамый,
Ак диярргә ярамый.
(*"Кара"(кара төс һәм боерык фигыль)*)

TURKISTAN KUTUBXONASI - ТУРКЕСТАНСКАЯ БИБЛИОТЕКА

* "Ч"га бетсә – очып китә, кош була,
"Н"га бетсә, бакчада җимеш була.
(*Карлыгач, карлыган*)

* Кайсы материк янындагы атауның (утрау) исемен кире яктан укысаң, гөл, чәчәк исеме килеп чыга?
(*"Азор", "роза"*)

* Чарлак кайчан кош була?
(*Акка буягач ("акчарлак")*)

* Күлмәкне икегә аерсаң, нәрсә килеп чыга?
(*Күл" һәм "Мәк"*)

* Азиядәге бер тауның исемен алам: беренче иҗеге – әйбернең төсен белдерә, икенче иҗеге – йорт хайваны исеме.
(*Алтай*)

* Беренче иҗеге – хайван,
Икенче иҗеге – боерык фигыль,
Икесе бергә – кош исеме.
(*Сыерчык*)

* Исеме ике сүздән ясалган. Беренчесе – җир йөзендә иң күп бер нәрсә. Икенчесе – кечкенә бер хайван; икесен бергә җыйганда, өен үзе белән йөртә торган бер хайванның исеме килеп чыга.
(*Ташбака*)

* Нинди сүздә алты "Н" бар?
(*Алтын*)

* Үзе биш хәрефтән тора торган сүз. Баштагы өч хәрефен генә укысаң, татлы әйбер исеме килеп чыга. Соңгы ике хәрефе – Татарстандагы елга исеме. Барысы бергә – суда яшәүче, бик тиз йөзүче.
(*Балык*)

* "Өч" дигәндә – ике була,
"Ике" дигәндә – өч була.
(*"Өч" һәм "ике" сүзләрендәге хәрефләр саны*)

* Алма дисәң дә алалар,
Нәрсә соң ул, балалар?
(*Алма*)

* Бер картка елганы көймәдә кичәргә кирәк. Аның юлдашлары – бүре, кәҗә, кәбестә. Көймәдә ике урын гына бар. Кәҗә кәбестәне, бүре кәҗәне ашамаслык итеп елганы ничек кичәргә?

TURKISTAN KUTUBXONASI - ТУРКЕСТАНСКАЯ БИБЛИОТЕКА

(*Карт башта кәҗәне көймәгә утыртып икенче ярга чыгара. Аннары кәбестәне алып кәҗә янына чыга. Кәбестәне калдырып, кәҗәне көймәгә утырта да бүре янына чыга. Аннары кәҗәне бу ярда калдырып, бүрене кәбестә янына чыгара. Соңыннан кәҗәне икенче ярга алып чыга*)

* Татарстандагы кайсы шәһәр суда йөзә?
(*Алабуга*)

* Иң кыска ай кайсысы?
(*Май*)

* Һәр хәрефе бер иҗек,
Исеме була ничек?
(*Аю*)

* Мәскәүдә бер дә юк, Казанда икәү.
(*"А" хәрефе*)

* Кәҗәнең башында нәрсә бар?
(*"К" хәрефе*)

* Көн белән төн уртасында нәрсә бар?
(*"Ө" хәрефе*)

* Мин – кояшта, мин – кыяда, ләкин тауда мин юк. Ул ни була?
(*"О" хәрефе*)

* Кое төбендә нәрсә бар?
(*"Ң" хәрефе*)

* Яз белән көз нәрсә белән тәмамлана?
(*"З" хәрефе*)

* Җирнең уртасында ни бар?
(*"И" хәрефе*)

* "У" белән язсаң, тау була,
"А" белән язсаң, диңгез була.
(*Урал, Арал*)

* Беренче иҗеге – боерык фигыль,
Икенче иҗеге – атау җөмлә,
Икесе бергә – кыйммәтле металл исеме.
(*Алтын*)

* Шәһәрдә бар, авылда юк,
Кешедә бар, адәмдә юк.
(*"Ш" хәрефе*)

TURKISTAN KUTUBXONASI - ТУРКЕСТАНСКАЯ БИБЛИОТЕКА

* Тыкрык башында ни бар?
(*"Т" хәрефе*)

* Алмагачның төбендә нәрсәкәй?
(*"Ч" хәрефе*)

* Бер иҗегем – төс минем,
Икенчесе – сыеклык;
Өченчесе болай ди:
– Безнең авыл бик бай, – ди.
(*"Ак "+" су"="Аксубай"*)

* Күлдә бар, елгада юк.
Үрдәктә бар, казда юк.
(*"Ү" хәрефе*)

* Барда юк, юкта бар.
(*"Ю" хәрефе*)

* Идел читендә ни күрәбез?
(*"И" хәрефе*)

* Тәрәзә төбе нидән гыйбарәт?
(*"Ә" хәрефе*)

* Корыда юк, суда бар; төтендә юк, буда бар.
(*"У" хәрефе*)

* Әбидә бер, бабайда ике.
(*"Б" хәрефе*)

* Чигәдә бар, кашта юк; чирәмдә бар, ташта юк.
(*"Ч" хәрефе*)

* Ташкент белән Уфада юк,
Әстерхан белән Самарада бар.
(*"Р" хәрефе*)

* Урманда бар, кырда юк,
Мунчада бар, өйдә юк.
(*"М" хәрефе*)

## X бүлек.
## Арифметик табышмаклар

* Ике кеше, кырдан сарыкларын куып кайтып килгәндә, бер су янында очраштылар. Боларның берсе карт, берсе яшь иде. Карты яшенең сарыкларына карап торды да әйтте: "Ишетәмсең, чибәр егет, әгәр син миңа бер сарыгыңны бирсәң, минем сарыкларым синеке чаклы ике була", - диде.
Егет, башын кашып, азрак уйлап торды да әйтте: "Юк, бабай, болай гаделсезлек булыр.

TURKISTAN KUTUBXONASI - ТУРКЕСТАНСКАЯ БИБЛИОТЕКА

Син үзең миңа бер сарыгыңны бир, ул чагында икебезнең дә тигез булып, арабызда көнчелек калмас", – диде.
Минем беләсем килә: боларның ничәшәр сарыгы бар иде?
(*Картның-җиде, егетнең биш сарыгы бар*)

* Бер төркем киек каз очып барганда каршыларына бер каз очрап: "Исәнмесез, йөз каз!" – диде. Болар "саумысыз" дип, исәнлек-саулык сорашканнан соңында, араларыннан берсе әйтте:
– Юк, энекәем, ялгышасың, без йөз каз түгел шул әле. Әгәр дә безнең чаклы тагын бер булса, тагын безнең яртыбыз чаклы булса, чирегебез чаклы булса, аның өстенә син дә килеп кушылсаң, менә шул чагында булырбыз йөз каз! – диде.
Беләсе иде:бу төркемдә ничә каз булган иде икән?
(*Утыз алты каз булган*)

* Бер кеше үзенең кечкенә улына әйтте ди:
– Улым! Мин сиңа бер йомыш кушам. Менә шушы акчага берәр тиеннән тавык йомыркасы, икешәр тиеннән үрдәк йомыркасы, өчәр тиеннән каз йомыркасы сатып алып кайт. Кара аны, ялгыш ала күрмә! – дип кулына бер сум акча тоттырып базарга җибәрде, ди. Шул бер сум акчага барысы алтмыш данә тавык, үрдәк, каз йомыркалары алып кайтты, ди.
Атасы:
– И, минем улым йомышка ярый башлаган икән инде! – дип әйтеп улының аркасыннан сөйде, ди.
Беләсе иде: бу бала тавык, үрдәк, каз йомыркаларын ничәшәрне алып кайтты икән?
(*Утыз данә тавык йомыркасы, егерме данә үрдәк йомыркасы, ун данә каз йомыркасы*)

* Бер бала ун тиенгә ун данә конфет алган. Конфетлар дүрт төрле, ягъни: данәсе ике тиенлек, бер тиенлек, ярты тиенлек һәм чирек тиенлек икән. Һәркайсыннан ничәшәр конфет алган?
(*Ике тиенлекне – ике данә, бер тиенлекне – биш данә, ярты тиенлекне – бер данә, чирек тиенлекне – ике данә*)

* Өч каләм – бер тиен, бер дәфтәр – ике тиен, бер карандаш – өч тиен тора. Әни миңа кырык тиен акча бирде дә, шул акчага кырык данә әйбер алырга кушты. Мин бу акчага кырык әйбер алдым.
Мин барлыгы ничә каләм, ничә дәфтәр, ничә карандаш алдым?
(*Егерме җиде каләм, сигез дәфтәр, биш карандаш*)

* Бер кеше мең сумга йөз баш мал алган. Ат – илле сум, сыер – утыз сум, сарык – биш сум тора. Бу кеше ничә баш ат, ничә баш сыер һәм ничә баш сарык алган?
(*Ун ат, ике сыер, сиксән сигез сарык алган*)

* Берәү иптәшенә әйткән: "Мә сиңа биш сум акча. Шуның белән базардан йөз баш кош сатып алып кайт. Каз – илле тиен, үрдәк – ун тиен, чыпчык – бер тиен тора", – дигән.
(*Бер каз, утыз тугыз үрдәк, алтмыш чыпчык алырга кирәк*)

* Бер кешенең алты улы булган. Аларның һәрберсенең берәр сеңлесе булган. Бу кешенең ничә баласы булган?
(*Җиде бала*)

TURKISTAN KUTUBXONASI - ТУРКЕСТАНСКАЯ БИБЛИОТЕКА

* Ике атага, ике улга өч йомырканы тигез итеп бүллергә кирәк. Берәр йомырка тисен. (*Бабай, ата, ул*)

* Бер укучы зоология бакчасына барып кайткан. Иптәшләре аңардан:"Бакчада нәрсәләр күрдең?" − дип сораганнар. Бу укучы:
− Попугайлар, антилопалар, мөгезборыннар күрдем. Ә күпме икәнен үзегез исәпләп белегез. Мин барысы уналты баш, унсигез мөгез һәм илле ике аяк күрдем, − дип җавап кайтарган.
Ул ничә попугай, ничә антилопа һәм ничә мөгезборын күргән?
(*Алты попугай, сигез антилопа, ике мөгезборын күргән*)

* Бер кеше сәгать кибетенә кереп сәгатьләр сайлый. Соңыннан бер сәгатьне күрсәтеп, хуҗадан сорый:
− Кыйммәтме?
− Ике йөз сум.
− Ә монысы?
− Монысы йөз генә сум.
− Төрегез алай булса шул йөз сумлыгын.
Ишектән чыгып барганда туктый да, яңадан хуҗага әйтә:
− Юк, мин монысын алмыйм, миңа менә бу зуры ошый. Күпме дигән идегез әле?
− Ике йөз сум.
− Мин бит сезгә йөз сум биргән идем.
− Әйе, дәхи бер йөз сум тиеш.
− Аның урынына алыгыз бу сәгатьне. Ул да бит йөз сум тора, − ди дә, баштагы сәгатен биреп, икенче сәгатьне алып чыгып китә.
Зур сәгать өчен ул күпме акча түләгән?
(*Йөз сум түләгән*)

* Бер кеше үзенең кечкенә улына: "Әй улым, мин сиңа бер йомыш кушам, яхшы тыңла. Менә шушы акчага берәр тиеннән тавык йомыркасы, икешәр тиеннән үрдәк йомыркасы, өчәр тиеннән каз йомыркасы сатып алып кайт. Кара, ялгыш ала күрмә, яме!" − дип, кулына бер сум акча тоттырып, аны базарга җибәрде, ди. Улы да, атасыннан акча алу белән, бзарга таба тыр-тыр йөгереп китте, ди. Барып шул бер сум акчага барысы алтмыш данә тавык, үрдәк һәм каз йомыркалары алып кайтып атасына бирде, ди.
Беләсем килә: бу бала тавык, үрдәк, каз йомыркаларын ничәшәрне алып кайтты икән?
(*Бала утыз данә тавык, егерме данә үрдәк һәм ун данә каз йомыркасы алып кайткан*)

* Унике кеше бергәләп җиде карбыз алганнар да, юл буенда бүләргә утырганнар. Һәркайсы бертигез өлеш алсын өчен, карбызларны ничек бүләргә белми аптырап торганда мәктәптән кайта торган бер бала очрап, ничек итеп бүлгәндә һәркайсына тигез тиячәгең өйрәтеп киткән. Бу кешеләр шулай эшләгәннәр һәм һәркайсы канәгать калган. Укучы бала аларга нинди киңәш биргән?
(*Дүрт карбызны өчәр кисәккә (унике кисәк була), өч карбызны дүртәр кисәккә (шулай ук унике кисәк була) бүләргә кушкан. Унике кешенең һәркайсы икешәр кисәк (берне зурны, берне кечкенәне) карбыз алган*)

* Бер кеше, трамвайга утыргач, җиде тиенлек билет өчен кондукторга бер сумлык кәгазь акча биргән дә, биш төрле акча кайтарып алган. Ул ничәшәр тиенлек акчалар кайтарып алган?
(*Илле, егерме, унбиш, биш һәм өч тиенлек акчалар кайтарып алган*)

TURKISTAN KUTUBXONASI - ТУРКЕСТАНСКАЯ БИБЛИОТЕКА

* Икмәк төяп калага баручы өч крестьян юлда бер йортка чәй эчәргә туктаганнар. Алар, хуҗа хатынга бәрәңге пешерергә кушып, йокларга ятканнар. Хуҗа хатын пешкән бәрәңгеләрне табак белән өстәлгә куйган да, үзе йорт арасында эшләр карарга чыгып киткән. Ул чыгып киткәч, юлаучыларның берсе торып бәрәңгеләрне санаган да, үзенә тиешле өлешне ашап яңадан йокыга яткан. Аннан соң икенчесе торган. Ул иптәшенең ашаганын белмәгән, калган бәрәңгеләрне тагын өчкә бүлеп, бер өлешен ашаган да, шулай ук йокыга яткан. Аннан соң өченчесе торып, иптәшләре ашап ятканны белмичә, калган бәрәңгеләрне тагын өчкә бүлгән һәм үзенә тигән бәрәңгеләрне ашап яткан.
Бераздан өчесе дә уянып карасалар, табакта сигез бәрәңге калган булган.
Хуҗа хатын юлаучыларга ничә бәрәңге пешергән?
(*Егерме җиде бәрәңге пешергән*)

* Авылдан килгән бер укучы, шәһәрдә квартир эзләп, бер кешегә кергән. Квартир хуҗасы аңа болай дигән:
– Әүвәлге айда бер сум, икенче айда ике сум, өченче айда өч сум, шулай ук уникенче айда унике сум түләрсең, – дигән.
Укучы шуңа риза булган, ләкин ул да бер шарт куйган:
– Син, – дигән укучы, – әүвәлге айда миңа ике тиен, икенче айда дүрт тиен, шул рәвешчә һәр ай саен алдагы айдан ике мәртәбә арттырып кайтарып бирерсең, – дигән.
Квартир хуҗасы моны бик юк кына акчага хисваплап, шуңар риза булган. Бер елдан соң исәпләшкәндә кемнән күпме акча чыгарга тиеш булыр?
(*Укучыдан – 78 сум, квартир хуҗасыннан 81 сум 90 тиен тиеш була*)

* Берәү улын базарга бер кәрҗин йомырка сатарга җибәрде. Аңар сатарга насыйп булмады: бер исерек бәрелеп, йомыркаларын ватты. Бала елап тавыш купты, казыйга(судья) хөкемгә килделәр. Казый баладан:
– Кәрҗинендә ничә йомырка бар иде? – дип сорады.
Бала әйтте:
– Мин ничә булганын белмим, анам кәрҗингә салганда икешәр-икешәр санады – берәү артты; дүртәр-дүртәр санады – берәү артты; бишәр-бишәр санады – берәү артты; алтышар-алтышар санады – берәү артты; җидешәр-җидешәр санады – артмады, төгәл килде, – диде.
Казый, исәпләп, ничә йомырка икәнен белде дә исеректән түләтте. Кәрҗиндә барлыгы ничә йомырка булган?
(*Өчйөз бер йомырка булган*)

* Абзардагы казлар һәм куйлар саны – алтмыш өч баш икән. Шуларның барысына ике йөз ун аяк. Абзарда ничә куй, ничә каз булган?
(*Кырык ике куй, егерме бер каз булган*)

* Диңгез уртасындагы кечкенә бер утрауда бер көтүче үзенең малларын көтеп йөргәндә, утрауның бер читеннән ут чыгып, җил уңаена иңләп, көтү өстенә килә башлады. Уттан котылырга әмәл юк икәнен белеп, көтүче бер хәйлә корды... Утрау бөтенләй янып бетте, әмма көтүче бөтен көтүне саклап калды.
Бу көтүче нинди хәйлә корган?
(*Алгарак барып ут төрткән дә, шул янып үткән урынга көтүне күчергән*)

* Агачка унике карга кунган. Аучы килеп икесен аткан. Агачта ничә карга калган?
(*Берәүдә калмаган. Икесе егылып төшкәч, башкалары очып киткән*)

TURKISTAN KUTUBXONASI - ТУРКЕСТАНСКАЯ БИБЛИОТЕКА

* Өч кеше шахмат уйнаганнар. Барысы өч уен уйналган, һәр кеше ничәшәр уен уйнаган?
(*Икешәр уен*)

* Биш кеше биш сәгатьтә биш метр канау казыганнар. Йөз сәгатьтә йөз метр канау казып бетерү өчен ничә кеше кирәк булыр?
(*Шулай ук биш кеше кирәк*)

* Әгәр төнге сәгать уникедә яңгыр яуса, җитмеш ике сәгатьтән соң көн кояшлы булырмы?
(*Җитмеш ике сәгатьтән соң яңадан төнге уникe була. Аяз булса да, кояш булмаячак*)

* Бер малай велосипедта шәһәргә бара икән. Аңа каршы машина очраган. Анда алты хатын утыра икән. Бер хатынның кәрҗинендә ике тавык, ә икенчесенең бер пар киез итеге бар икән. Барлыгы ничә җан иясе шәһәргә бара?
(*Шәһәргә малай үзе генә бара. Машинадагылар шәһәрдән кайта*)

* Бер самолет "А" шәһәреннән "Б" шәһәренә бер сәгать егерме минут оча. Икенче самолет кирегә – "Б" шәһәреннән "А" шәһәренә сиксән минут оча. Кайсы тизрәк оча?
(*Сиксән минут – барыбер бер сәгать егерме минут*)

* Балык ярым – тиен ярым. Ике балык ничә тиен?
(*Ике тиен*)

* Ике сигез – уналты,
Тагы сигез, тагы алты.
(*Утыз*)

* Ике сигез – уналты,
Янә сигез, янә алты.
Ике алты, бер сигез,
Бер егерме, бер утыз.
(*Йөз*)

* Биш бишең бер төштә,
Ике бишең бер төштә,
Бер сигез дә бер тугыз,
Бер егерме, бер утыз.
(*Йөз дә ике*)

* Өчәү-ечәү еч төштә,
Берәү генә бер тештә.
(*Ун*)

* Кырда кырык багана,
Баганалар саен кырыгар бoжра,
Бoжра саен кырыгар ат,
Барысы ничә ат?
(*Алтмыш дүрт мең ат*)

* Утыра, ди, дүрт мәче,
Һәр мәче алдында – өч мәче,

TURKISTAN KUTUBXONASI - ТУРКЕСТАНСКАЯ БИБЛИОТЕКА

Һәр мәченең койрыгында – бер мәче,
Барысы ничә мәче булган?
(*Дүрт мәче булган. Алар өйнең дүрт почмагында утыралар, һәр мәче үзенең койрыгында утыра*)

* Биш алманы биш кешегә берәр алмадан бүлегез дә, берсе кәрҗиндә калсын.
(*Бер кеше алманы кәрҗине белән ала*)

* Ике күлмәкне бер айда өч кешегә егермешәр көн кидерергә кирәк.
(*Икешәр-икешәр кеше,чиратлашып, унар көнләп кияләр*)

* Бер агачка сандугачлар килеп кунган, һәр ботакка икешәр сандугач кунса, бер ботак җитми. Өчәр кунса – дүрт ботак артып кала. Ничә сандугач һәм ничә ботак булган?
(*Ундүрт ботак, утыз сандугач*)

* Очкан өч карга,
Кунганнар талга,
Өчәү кунса, бер тал артып кала,
Берәмләп кунсалар, бер карга артып кала,
Ничә карга, ничә тал? –
Җавабын үзең табып ал.
(*Өч карга, ике тал*)

* Йөз аршынлык баганага таракан менә. Көн буена утыз аршын өскә күтәрелә, әмма төн буена егерме аршын аска төшә. Бу таракан багананың башына ничә көндә менеп җитәр?
(*Сигез көндә. (Баштагы җиде көн һәм җиде төндә җитмеш аршын юл үтә. Сигезенче көнне калган утыз аршынны күтәрелә дә багана башына менеп җитә)*)

* Бер малай туган. Әтисе аның туган көне саен дүрт сум акча сала барган. Акча егерме сумга җиткән җитүен, улы ничә яшендә өйләнгән була соң?
(*Егерме яшендә. Ул кәбисә елында, 29 февральдә туган була*).

* Бер баладан: "Син ничә яшьтә?" – дип сораганнар. Ул:
"Яшемнең саннарын алыштырып куйсагыз, утыз алты яшькә зураермын", – дигән. Бу бала ничә яшьтә?
(*Унбиш яшьтә*)

* Берәүдән: "Син ничә яшьтә?" – дип сораганнар. Ул: "Әгәр дә минем яшемнең яртысына биш саны кушылса, моннан унөч ел элек миңа ничә яшь булганын табарсыз", – дигән.
Ул хәзер ничә яшьтә була?
(*Утыз алты яшьтә*)

* Чакта, чакта,
Әти утыз икедә чакта,
Миңа сигез яшь иде ул чакта.
Хәзер әти миннән ике тапкырга олырак,
Миңа ничә яшь? Аңа ничә яшь?
(*Егерме дүрт һәм кырык сигез яшь*)

* Бер мужик үз алпавытының җирендә ау аулап йөргән чагында хуҗасының кулына төшкән. Хуҗасы бу эш өчен аны асарга хөкем иткән. Мужик ялынырга тотынган. Алпавыт: "Әнә тегендә су белән туп-тулы бер тәпән тора. Һичбер чит аләтсез (корал) шул суның төгәл яртысын түксәң, коткарырмын", – дигән.
Мужик, бераз исәпләп торгач, тәпән янына килеп, хуҗасының күз алдында суның төгәл яртысын түккән дә котылган.
Ничек итеп тәпәннең төгәл ярты суын түгәргә мөмкин?
(*Тәпәнне әкрен генә аудара, төбе күренә башлагач туктый*)

**XI бүлек.**
**Нәкый Исәнбәт. Отканга – мәкаль, тапкырга – табышмак**

Табышмак ике кисәктән тора: берсе – табышмагы әйтелү; икенчесе – чишелеше – җавабы. Табышмагын берәү әйтсә, җавабын икенче берәү табып әйтә (Яки күмәк эченнән берәүләр.). Һәр табышмак шулай табыла. Берсеннән башка икенчесе булмый. Чиләгенә күрә капкачы. Яки алар ачкыч белән йозак шикелле. Табышмак аның йозагы, эченә мәгънә бикләнгән, табучы аңа үз акылы, үз зирәклеге белән ачкыч табып ачып керергә тиеш. Ләкин ул шундый хәйләле йозак ки – ачкычы читтә-нидә түгел, шул йозакның үзендә! Белмим, ул аның тышкы күренешендәме, эчендәме, тышындамы, әллә әйтелешендәме, кай җирендәдер ишерелгән...

Табышмак әйтешү ул миндәге табышмакның җавабын синдә (яки, киресенчә, синдәге миндә, аңарда) табу. Ул бикле йозак булса да, үзе кечкенә матур бер сөйләм, җавабы исә аның эчке мәгънәсе, ләкин ул шул ук вакыт аның эчендә дә түгел, конкрет исемле бер әйбер. Бу исем аның темасы. Шуны атап әйттең исә, йозак үзеннән-үзе ачыла. Димәк, форма аша эчтәлек табыла. Бу табышуда сүзнең хәтердә тудырган өстәмә сурәтләре аша төп мәгънә эзләнгәнгә күрә, бу инде гади мәсьәлә чишү генә булып калмый, бәлки психик катлаулы иҗади бер процесс була...

Табышмак күмәк эчендә башкарылгач, билгеле, кем дә булса берәү тизрәк табып җавабын әйтүе аның акыл, зиһен, хыял җитезлеге шәбрәк булуын күрсәткәнгә, билгеле бу эш егетлек санала. Шунлыктан җавабын табу күмәк өчендә ярыш кызуын һәм дәртлелелеген уята. Кайчагында шулай тырышып җавабын тапкач, синнән әллә ни гомер үзен эзләткән табышмакның җавабы шундый гади, менә торган әйбер генә булып чыккач, үзеңнең аңа "махы биреп" торуыңа аптырап каласың.

Табышмак шулай чишелгәннән соң, кызыксыз, гади, җиңел әйбер кебек кенә булып кала. Күрәсең, аның кызыгы шушы мәгънәсен ачу процессының үзендә. Ләкин моңа карап аның шигъри әсәр булуы һәм икенче урында икенче авыздан икенче берәүләргә әйтелеп мәгънәсен эзләгәндә, тагын шундый ук кызыклы булуы һич тә кимеми. Чөнки ул барыбер сурәт аша мәгънә эзләү булганга, табучы өчен гади мәсьәлә чишү булып кына калмый, һаман да мавыктыргыч кызыклы, поэтик иҗади процесс була. Бу процесста безнең хыялыбыз бик тиз хәтер сандыгыбызны барлап актарырга һәм моның өчен минут эчендә бик күп урын-ара җирләр, бәлки, күңел космосларын кичеп үтәргә тиеш була.

***1. ТАБЫШМАКЛАРНЫҢ ХАЛЫК ПЕДАГОГИЯСЕНДӘ ТОТКАН УРЫНЫ.***

TURKISTAN KUTUBXONASI - ТУРКЕСТАНСКАЯ БИБЛИОТЕКА

Табышмакны хәзер иң яратып әйтүчеләр кемнәр дисәгез, әлбәттә, балалар дияргә туры килә. Бигрәк тә яшүсмерләр. Олылардан аны берән-сәрән генә әйттереп була. Балалар исә зурлар авызыннан өзеп-йолкып ала һәм, узара да әйтешә торгач, һәркайсында күпме дә булса табышмак запасы җыела, ансы һәр баланың үз дәртлелегенә, үз җитезлегенә карап. Шуңа күрә, гаҗәпкә каршы, табышмакны иң күп белүче дә балалар, яшүсмерләр. Хәзер ул алар репертуары булып киткән.

Кешеләр буй үстереп, тормышка аяк басып алдылармы − аларда табышмак кайгысы булмый, эшкә баталар, дөнья куалар. Урта яшьлеләр бигрәк тә. Кайда анда! Яшьлектә иелгән табышмаклары да күбесе шыбырдап коелып бетә. Шулай итеп үзләре балачакта әби-бабайлар авызыннан берәмләп булса да табышмак җыйган ул балалар менә бер көнне, картайгач, үз хәтерләрендә калгалаганын тагын балачагага әйтә башлыйлар. Шул берәм-сәрәмнән дәртле балалар, яшьләр телендә тагын репертуар җыйнала, үстерелә, кайберлөре онытыла, яңалары чыга бара. Искеләре аз-маз үзгәрсә дә, күпмеседер, телдән төшеп калмыйча, саклана ала. Шул юл белән безнең телдә сакланып килгәннәре татар табышмакларының алтын фондын хасил итәләр.

Менә шул ата-бабаның буыннан буынга һәм үз хәтерләренчә, үз белмешләре буенча әйтеп килгән бу кадерле әсәрләрнең янәдән балалар, яшүсмерләр теленә әйләнеп кайтып торуында заманнар аша килеп торган бер әйләнеш бар. Аның шулай һәм югала, һәм саклана килүендә, ягъни бу диалектик каршылыкның үзендә безнең өчен зур мәгънәләр ята. Чөнки үз туган халкыңның ата-бабадан килгән бу кадерле мирасларын белмичә, алар тәҗрибәсе белән коралланмыйча, аларның күңел байлыгы булган поэзия белән баемыйча торып, без үзебез дә бернинди киләчәк байлыкларга юл ача алмыйбыз. Табышмаклар исә, иң элек балачага, яшүсмерләр репертуары буларак, балаларның акыллары, күңел дәртләре, телләре дә шул байлыклар белән баеп, камилләшеп, табигатьләре һәм зәвыклары җитеш булып, бөтен булып үсүендә бик кирәкле, бик әһәмиятле роль уйныйлар. Шулай итеп, ул − балалар, яшьләр өчен зарури бер сәнгать.

Табышмаклар шулай әйтергә бик кечкенә әсәрләр булса халык аларны хәзер дә әйтеп, телдә саклап килүе, әлбәттә, юкка гына түгел. Күрәсең, ул халык педагогиясендә хәзердә дә үзенчәлекле, әһәмиятле роль уйный. Балалар өчен аның шундый мавыктыргыч кызыклы, әдәби, иҗади һәм зарури булуын тәрбиячеләр белгәннәр һәм дәреслекләргә кертә килгәннәр. Мәсәлән, русларның мәшһүр педагогы Ушинский үзенең төзегән әлифба китабында табышмаклардан бик оста файдаланган.

## *2. ТАБЫШМАКЛАРНЫҢ КҮҢЕЛ АЧУ ҺӘМ ЭСТЕТИК ЗӘВЫК БИРҮ ЯГЫННАН ӘҺӘМИЯТЕ.*

Иң элек табышмакны, гадәттә, кич белән йоклар алдыннан әйтәләр. Чөнки көндез олылар да, балалар да мәшгуль. Олыларның үз эше, балачаганың әлеге шул уку-язу, спорт, уен яки башка шөгыльләр. Менә бер заман кичкырын өйгә кайтып, ашап-эчкәч, йокыга кадәр гадәттә кешенең ял сәгате башлана. Туган-тумача үзара көндезге тәэсирләрен сөйләшә, куанычларын, көенечләрен бүлешә. Берәүләр бу вакыт җиңелчә генә кул эше ала, икенчеләр берәр кызык хикәя укый, тагын берләре, көндезге "аруын чыгарып" аунап ята башлый. Шул чагында кешедә кызык кына хыяллар уяна, тел дә тик тормый, шул эшкә катыша... Ә кеше мие шундый: аның эшчәнлеген үз иркенә куйганда да, үз инстинктына буш җибәргәндә дә, аның мөмкинлегенең чиге юк: андагы күңеленә килгән нәрсәләрне

TURKISTAN KUTUBXONASI - ТУРКЕСТАНСКАЯ БИБЛИОТЕКА

әйтеп сөйләп бирергә дә әкиятчә бай, әкиятчә киң тел кирәк, күңел ачкыч яңа сүзләр кирәк, я күңелләрдә тулышкан моңны түгәр өчен көй, музыка, җыр кирәк. Бу бигрәк тә яшь көчләр өчен кирәк. Берни әйтер хәл юк, чөнки бу бит инде кешедәге рухи таләп. Шуның белән олылар да кичке ял сәгатьләрендә театр, кино, цирк яки башка тамаша йортларына китеп баралар. Әмма кичен андый тамаша урыннары булмаганда, йә гел китап та телевизорлар белән мавыгудан туйганда, бигрәк тә авылда, балалар, яшьләр арасында табышмак әйтешү безнең бүгенге фән-техника заманында да бик күңелле шөгыльләрнең берсе. Чөнки кичен шул көндезге арулардан арыну өчен, уртада шул хыял учагын бер кабындырып җибәреп, аның янында күңел ачу өчен, әнә шул зиһен-хыял эшләтүләр кирәк. Менә шул иҗади, рухи таләпне җиңелчә бер үтәп алу өчен табышмак иң җайлы һәм җиңел бер репертуар булып тора.

Җиңелчә үтәү, башкару дигәч тә, бу сезгә һәр табышмак та җиңел табыла дигән сүз түгел. Ул сүз монда табышмак уенының берникди гримсыз, декорациясез кыска бер реплика сурәтендә бирелеп уйналуы өчен әйтелә. Чөнки бит табышмак әйтешү дә үзенә күрә уен. Аны әйтешүнең үзендә үк балаларның яраткан "качыш" уены бара. Чөнки бит безнең алдыбызга тамашага аның табышмагы гына куела. Җавабы пәрдә артына качкан! Икенче төрле әйтсәк, мәгънә сурәт артына качкан. Күрәсез, табышмак үзе бармак бите хәтле генә булса да, анда качыш уйнарлык кечкенә "сәхнә" бар, шул мәгънәне эзләү, табу, тотып алу дигән "интрига" бар, ул мәгънәне яшергән "пәрдә" бар, "маска" бар. Я, менә хәзер кайсыбыз тизрәк шул сурәт артына качкан мәгънәне эзләп табар?

Җавап сиңа үз койрыгын тиз генә тоттырмый. Качыш дәвам итә... Чөнки бит табышмакны табучы бер син генә түгел, гадәттә, ул күмәк эчендә бергә үтәлә. Үз-үзеннән ярыш китә. Бу теләсә ни ярышу түгел, үзеңне акыллымын дип белсәң, тиз генә табып күрсәт! Хәер, кем инде үзен юләр санасын ди? Киресенчә, һәркем үзен акылга үткен, хәйләгә остарак дип белә. Хикмәт шунда, бу, табышмак дигәнең җиңел әйтелсә дә, аның үзе белән җавабы арасында нииндидер каршылык коймалары бар булып чыкты... Син табышмакның җавабын табам дип, аның үзе белән дә, анда бирелгән сурәт һәм яшерен мәгънә арасындагы каршылык белән дә конфликтка керәсең. Синдә хәзер шул табу комары. Бу инде төрле рәсем-сурәтләр арасыннан үзең эзләгән, үзең яраткан бер сурәтне табып алу кебек татлы, югары бер ләззәт, эстетик ләззәт. Таба алсаң, синең зиһенең иң житез, синең хыял иң йөгерек. Отыш синдә. Ә табалмасаң, сынаттың. Уен булса да сынаттың!

Чөнки табышмакның үзе кечкенә булса да, ул синең белән юкка гына качыш уйнамый. Чөнки уен булса да бу сиңа − имтихан. Синең хыял, хәтер-зиһен җитезлегең сыналды. Күрәсең, ул уйнап әйтелсә дә чынлап әйтелә. Бу бик мөһим. Аның борынрак һәртөрле йолалар, мәҗлесләр белән үткәрелүе әнә шул үзенчәлекле әдәби эстетик зәвыклылыгы һәм зиһен сынаш әйбере булуында да.

## *3. ТЕЛ ЯГЫННАН ӘҺӘМИЯТЕ.*

Табышмакның үз тумышы һәм табигате буенча шигъри телнең үрнәге, җанлы, сурәтле сөйләмнең тарихтан килгән нигезле бер күренеше икәнен күреп үткән идек. Инде ул барлык чагыштыру, тиңләштерү, киная, метафора, охшату, җанландыру (сынландыру дип аңларга кирәкми. Мисал: "ай көлә" дисәк, ай сыйланмый, бәлки җанлана) һәм башка барлык троп, телбизәк чаралары белән эш иткәнгә һәм үзе дә архаик сүзләр белән бергә яңа сүзләр ничек ясалуның бер үрнәге булганга, ул безнең тел-сүз казнасы, аның

TURKISTAN KUTUBXONASI - ТУРКЕСТАНСКАЯ БИБЛИОТЕКА

арсеналы. Ул безне тел байлыгыбыз белән таныштырып кына калмый, аның шигъри алымнары һәм сурәтләү чаралары безне дә җанлы тел белән эш итәргә, тел остасы булырга күнектерә.

Табышмак үзенең тел байлыгы, җанлылыгы, сурәт һәм мәгънә килешлеге, афористик әйтелеше белән шигъри мәктәп булып тора. Ул бу сурәтлелеге һәм мавыктыргычлыгы белән балаларның зәвыкларын гына үстереп калмый, шулар өстенә аның табигатьтән алынган төрле охшату, чагыштыру, паральлеләр аша табигатьнең үзен дә яратырга өйрәтүләре − болар бар да табышмакларның эстетик тәрбияви роле гаять зур булуын күрсәтә.

Сәнгатьчә аерымлыкларына килгәндә, табышмакларда тагы метафора, аллегория, синекдоха, гипербола, омоним, охшату, антропоморфизм, чыгармалар, карикатура, тавышка иярүләр, аллитерация һәм башкаларның тоткан урыннарын күрсәтергә мөмкин.

*Метафора. (Алмаштыру).* Табышмакларда моның нигез урын тотуы башта әйтеп үтелгән иде, детальләрдә дә бу шактый еш күзгә ташлана. Мәсәлән: "Баш астында баллы кашык" дигәндә, йокыны баллы кашык белән, "Мич тулы пәрәмәч, уртасында бер калач" дигәндә, күк йөзе, йолдызлар һәм айны мич, пәрәмәч һәм калач белән алыштырып алу шикелле.

*Аллегория.(Киная).* Фикри мәгънәләрне читләтеп конкрет сурәттә бирүгә мисал итеп, Сәрвиназ әкият-табышмагын күрсәтергә була. Анда, мәсәлән, сүз йөртүченең ике теле дигән төшенчә урынына ике бүре һәм җан дигән төшенчә урынына алтын йөзек алынган. Сүз бөтенләй читтәге бер вакыйга турында барган кебек итеп бирелә.

*Синекдоха.* Мәсәлән: "Мең баш елкыны бер чыбык белән әйләдем" дигәндә елкыны бөтен гәүдәсе урынына башы белән генә санау.

*Мәгънәдәш сүзләр.(Ике аерым мәгънәле омонимсүзләр).* Мәсәлән, казан турындагы табышмакта "Һәммә татар өендә бар, үзе дөньяда бер генә" дигәндә казан сүзенең ике мәгънәдә алынуы шикелле.

*Гипербола.(Арттыру).* "Метри башлы, мең күзле" (уймак); "Элек балчык тавы, аннары тимер тавы..." (мич, таба) дигәндәге шикеллеләр.

*Охшату.* Бик күп очрый: "Үзе актай, корсагы каптай..." (кәҗә); "Койрыгы без кебек, күзе тоз кебек" (тычкан) һ.б.

*Антропоморфизм.(Кешеләтү).* Көзге турында: "Кечкенә генә Микитә, бер кешене ике итә"; куян, эт һәм пычак турында: "Урманнан чыгар, койрык очы чуар, Бикәнәе тотар, Биктимере суяр" дип әйтелүләр шикелле. Мондый табышмакларда күмәк исемнәрнең ялгыз исемнәргә күчерелүе еш очрый икәнен дә әйтеп үтәргә кирәк. Мәсәлән, шул ук табышмакларда көзгене Микитә, пычакны Биктимер дип алу шикелле.

*Чагыштыру.* "Балалары тererәк, аналары хуш күңеллерәк" (чынаяк, самавыр).

*Кире кушарлау.(Акад. Веселовскийча − кире параллелизм).* "Авызы бар, теле юк..."(чабата); "Агач түгел, яфраклы"; "Тун түгел, тегелгән" (китап) һ.б. Бу алым бик киң урын ала.

TURKISTAN KUTUBXONASI - ТУРКЕСТАНСКАЯ БИБЛИОТЕКА

*Карикатурачылык.* Табышмакларның бу ягы әлегә чаклы бер җирдә дә телгә алынуын мин күрмәдем. Ләкин карикатурачылыкның халык иҗатында урын тотуын билгеләп үтү әһәмиятсез булмас. Мәсәлән, кеше гәүдәсе турындагы табышмакны алыйк: "Ике багана, багана өстендә мичкә, мичкә өстендә бөке, бөке өстендә шар, шар өстендә куаклык", моның юри кабартылган чалымнарда бирелгән карикатура икәнен күрү өчен, шул бирелгән сызыкларны кәгазьгә төшереп карау җитә.

*Тавышка иярүчелек.* "Дөп-дөп дөбер Гали, Булгалый, шып-шып шыбыргали, боргалый" (ашлык сугу) һәм башкалар.

*Корамалык.* Шул ук тавышка иярүләр аркасында мәгънәсез сүз корамаларыннан торган табышмаклар да очрый:"Лып-лып ихыл, шрихыл да шрифыл... "(карбыз кисү).

*Аллитерация.(Бер үк төсле тартыкларның чиратлашыпкилүе).* "Базы туза, баганасы кала", "Йөзлек астында йөз инә" һ. б.

## *4. ЗИҺЕН ТИЗЛЕГЕН ҺӘМ ИГЪТИБАРНЫ ҮСТЕРҮЕ.*

Табышмаклар үзләрен таптыру өчен кешенең хәтер сандыгын актартып, андагы нәрсәләрне охшашлыгы буенча ишен ишкә китереп табу булганга, бик тиз зиһен йөртүне таләп итәләр. Бигрәк тә күмәк эчендә аны табышу ярыш төсендә барган чагында. Зиһен җитезлеге кешенең хәтер байлыгына, хәтер байлыгы исә аның нәрсәләргә игътибар һәм дикъкать итүчәнлегенә, игътибар исә кешенең үзенә кирәк нәрсәне тиз сайлап алу һәм аны белергә тырышуына, болар барысы бергә кешенең хәтере җыйнак һәм үткен булуына бәйләнгән. Кешенең хәтере үткен булуы исә аның рухи көчләре бер үзәккә тупланган һәм аның ихтыяр көче нык булу дигән сүз. Ихтыяр тәрбиясе кеше тормышында иң мөһим урын тота икәнен әйтәсе дә юк. Шул рәвешле табышмак әсәр булса да, аны табу кеше миенең хәтер һәм ассоциация өлкәсен бик нык биләп алганга, логик фикерләүнең барлык категорияләре буенча уйны һәм уй өстенә хыялны йөгерткәнгә алар зиһенне үстерәләр, хәтерне үткенәйтәләр, аны чакыру, идарә итү көче, ихтыяр көчен ныгыталар.

Моңа өстәп тагын шуны да әйтергә кирәк: авыз иҗатының гомумән башка төрләреннән булган озын-озын әкиятләрне, бәетләрне, көе белән җырларны яки бу вак жанр аталган мәкаль-табышмакларны һәм башкаларны бер ишетүдә отып алу, аны тагын үз алым, үз әйтелешләре белән яңадан үзеңчә иттереп сөйләп чыга белүчелек тел һәм хәтерне нык үстерә. Бу исә фольклорның игътибарны һәм зиһенне тәрбия итү ягыннан да педагогик әһәмияте зур булуын күрсәтә. Табышмак исә аның үзен хәтергә алу белән генә чикләнмичә, үзенә җавап таптыру өчен хәтернең үзендә кызу-кызу чагыштырулар белән эзләткәнгә, ул хәтерне тәртипле һәм ысуллы булу ягыннан да тәрбия итә.

## *5. ЭТНОГРАФИК ӘҺӘМИЯТЕ...*

Табышмакның бездән таптырган нәрсәләре, аласы җаваплары бар да тормышта элек тә һәм хәзер дә кулланылган нәрсәләр. Менә шулардай халкыбызның материаль культурасы элек һәм хәзер нәрсә-нәрсәләрдән торганын, халык ул нәрсәләрне табигатьтән һәм табигатьтәген үзендә булган нинди нәрсәләр белән чагыштырырга һәм ничек

TURKISTAN KUTUBXONASI - ТУРКЕСТАНСКАЯ БИБЛИОТЕКА

чагыштырырга яратканын, аның кәсеп, һөнәрләрен, − өй тормышын, кием-салым, ашау-эчү нәрсәләрен, юаныч әйберләрен, мәктәбен, сугыш коралларын һәм башка техникасын, транспорт-элемтә чараларын, кыскасы, барын да, барын да күзаллап була. Халык табышмакта нәрсәләр белән күбрәк кызыга? Бу хакта һәр аерым нәрсәгә күпме табышмак бирелүе дә игътибарга лаек. Мәсәлән, бу китапта (Татар халык табышмаклары, Казан, Татарстан китап нәшрияты, 1970) табигать дөньясыннан алынганнары (борынгылар бүлегендәгене дә бергә кушып исәпләгәндә) түбәндәгечә: яшен һәм күкрәүләр турында 27 табышмак; кар-буран турында − 3; чикләвек − 30; суган −16;... балкорты − 51;...

Кеше кулы белән ясалган механизм-машиналар безне табигать дөньясына караганда да ныграк кызыксындыра дияргә була. Мәсәлән: тегермән турында − 34, сәгать турында − 64 табышмак!

Өй җиһазы, кул эшләре, савыт-сабалар турында − 29, себерке турында 33 табышмак!..Татарның, әлбәттә, инде иң яратканы иртә-кич, гаиләсе белән бер табын корып, чәй эчү. Уртада − аларны чакырып, дәрт биреп торган гайрәтле самовар. Җиз самовар. Көмеш самовар... Ул нинди-нинди нәрсәләргә охшатылмый да нинди сурәтләрдә генә әйтелми! Һәм татар табышмакларының иң күп әйтелгәне дә (сәгатьтән кала) самовар турында: 61 табышмак! Әйтик, русларда иң тулы Садовников җыентыгында самовар турында 8 табышмак күренә.

Чәй турында анда 3 табышмак китерелгән. Дикъкать белән карасаң, мондый күпләгән табышмакларда һәр халыкның үз милли зәвыгы, милли үзенчәлеге һәр яклап күзгә бәрелеп күренеп тора.

Татарның элек-электән гыйлем-мәгърифәт яраткан мәдәниятлы халык булуы китап-каләм, язу турында борынгы һәм хәзерге табышмакларның күп булуында да күренә: каләм-кара, язу турында − 50, китап − 20, хат язышу турында 13 табышмак...

Кайбер этнографларның фольклорны үз әдәби кыйммәте булган авыз иҗаты итеп караудан бигрәк үз фәннәреннән санаулары аның шулай этнография малы итеп кенә калдырырга ярамый. Сәбәбе, югарыда әйтелгәнчә, аның үзкыйммәт иясе һәм бик әһәмиятле әдәби бер авыз иҗаты әсәре булуында.

## *6. ТАРИХИ ӘҺӘМИЯТЕ.*

Табышмаклар мең елдан, кайберләре, бәлки, аннан да элегрәктән калып саклана һәм бу көнгәчә, яңалары өстәлә барып, дәвам итеп килгән булгач, бу хәл үзе үк аларның тарихи әһәмиятләре булуын күрсәтә. Бу әһәмиятлелек бер генә яктан түгел. Әйтик, беренчедән, табышмаклар үзләрендә булган борынгы архаик сүзләрдән алып, бу көнгәчә дәвам иткән тел байлыгы һәм элеккеләр өстенә яңа сүз иҗатчылыгы белән дә баеп, эшләнеп килгән бер жанр булганга, тел белеме, тел тарихы ягыннан караганда, әлбәттә, бик мөһим; икенчедән, табышмакларда чагыштыруларда китерелгән һәм җавапларында әйтелгән нәрсәләр буенча без халкыбызның үткән мәдәният баскычларын, аның материаль культурасын һәм этнография тарихын өйрәнергә дә материаллар табабыз. Өченчедән, табышмаклар кешеләрнең табигать белән иҗтимагый үзара мөнәсәбәтләрен, аларның төрле чорларда төрле дәрәҗәдә торган булуларын күрсәтүе белән без халкыбызның психологик үзенчәлеген һәм дөньяга карашының тарихи килешен дә шактый күзаллый алабыз. Шулар

TURKISTAN KUTUBXONASI - ТУРКЕСТАНСКАЯ БИБЛИОТЕКА

өстенә табышмакларның татар халык авыз иҗаты әсәрләре һәм фольклорыбызның үзенчәлекле бер төре буларак, үз тарихи килешен өйрәнү зур бер әһәмияткә ия булып тора.

### *7. ТАБЫШМАКНЫҢ АКЫЛ-БЕЛЕМ ТАБУ ЮЛЫ БУЛУЫ, ЛОГИК ФИКЕРЛӘҮНЕ ҮСТЕРҮ ЯГЫННАН ӘҺӘМИЯТЕ.*

...Табышмаклар чагыштыру, охшату, тиңләштерүләр аша нәрсәләрне сыйфат һәм хасыятьләре буенча төрләргә бүләргә, аерырга һәм уртак сыйфатны табу аша үзен табарга, үзен билгеләргә өйрәтәләр. Табучы таба алмый торса, "Ул әйбер нәрсә затыннан? Нәрсә җенесеннән?" дип сораулары белән кеше әйбернең затын затка, җенесен җенескә, ягъни логик категорияләргә аерып карарга күнегә. Шунысы кызык, ул моңа махсус логика фәнен укып түгел, бәлки, табышмак белән мавыгу аша, "үзеннән-үзе" күнегә. Элементар рәвештә булса да, табышмаклар логик фикерләүгә шактый кыю керәләр. Алар арасында кара исәп табышмаклары дигән бер бүлек турыдан-туры арифметик фикерләүгә корылган. Табышмакта билгелелек белән билгесезлекне табу бар. (Мәсәлән, туганлыкны табышуларда). Димәк, табышмакларда логик һәм математик фикерләү юлы, белем орлыгы да бар дигән сүз һич тә корыга гына әйтелми. Бу да аның әһәмиятле бер ягы.

Шулай итеп табышмакларны әйтешү, табышу аша кеше әйберне әйбергә чагыштырып, бер-беренә охшашлыкны үлчәргә, алар арасындагы уртак сыйфатны тиз тотып алырга, асылына ирешергә өйрәнә. Табышмак шул рәвешле сурәт аша мәгънә табу, форма аркылы эчтәлекне күрү булганга, шуның белән ул шигырь тану ачкычы, кешедәге шул сизгерлекне, шул тойгыны уятып зәвыкландыручы.

Табышмак әдәби зәвык һәм эстетик ләззәт тойгысын бирүе белән менә нигә яшьләр һәм балалар өчен бик мөһим тәрбияви роль уйный. Шуңа күрә бала-чаганың табышмакка ябышып ятуы һич тә бушка түгел. Ул аларның рухи, мәгънәви ихтыяҗларын үти.

Табышмак үзе кечкенә әсәр булса да, җавабы аерым ишарәләр һәм күп кенә төрле чагыштырулар аша табылганга, аның мәгънәсе үзенең тар текстына сыешып кына калмый. Ул аннан күп мәртәбә киңрәк, баерак. Дөрес, без аны кече форма фольклор, чәнти (бәләкәй) жанр дип йөртәбез. Ләкин мәгънәсе һәм аның ясаган тәэсире үзенә тотылган вакыт белән дә үлчәнсә, аны вак әйбер дип кенә карарга бирми. Чөнки бит кайчагында без аның җавабын көннәр буе да эзлибез. Мәсәлән, үзебез таба алмаган, читтән дә безгә әйтүче булмаган чакларда. Икенче төрле әйткәндә, бер авыз сүздән торган табышмакны бер көн буена укыган булабыз. Зиһенебезне шулкадәр мәшгуль һәм тоткар иткән бу әсәргә кайчак шулай бер роман укырлык вакыт китә торган булса, аның турында "Үзе кечкенә, эче төш кенә" дигән сүз бик туры килә.

http://www.turklib.ru

http://www.turklib.uz

TURKISTAN KUTUBXONASI - ТУРКЕСТАНСКАЯ БИБЛИОТЕКА

http://www.turklib.com

TURKISTAN KUTUBXONASI - ТУРКЕСТАНСКАЯ БИБЛИОТЕКА